ЭШ БАР

Авылда механизатор, сыер савучы, агроном, зоотехник һәм мал табиблары җитми

> 6

ӘНИЛӘР ҺӘМ БӘБИЛӘР

«Ак чәчәкләр» бәйгесенең махсус бүләге иясе, акушер Елена Родионова белән таныштырабыз

> 7

АЛИНӘ ШӘРИПҖАНОВА:

«Мин алдаша алмыйм – бөтен бәла шунда»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 88 (29055) | Җомга | 23 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ӘЙЛӘНЕЧТӘН ТИЗРӘК

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ ЯҢА ЮЛ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮРЕП КАЙТТЫ

Киләсе елда Казан белән Түбән Кама арасы бер сәгатькә якынаячак. Уйдырма түгел бу. Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы төзелеп беткәч, әйләнечтән юл турырак та, тизрәк тә булачак, ди белгечләр. Әлеге эш кысасында Чулман елгасы аша гына да 23 миллиард сумлык күпер салалар әнә. Аның аша машиналар киләсе ел ахырында ук хәрәкәт итә башлаячак дип фаразлана. М12 югары тизлекле трассасыннан соң, Татарстандагы иң зур һәм иң әһәмиятле юл төзелешеннән безнең репортаж.

> 5

Ишетми калмагыз

Татарстанда машина йөртүчеләр, инженерлар һәм табиблар җитми. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова әйтте.
Әйтик, республикада 2335 йөртүче кирәк. Уртача хезмәт хакы – 38504 сум. Инженерларга 1211 вакансия бар. Уртача хезмәт хакы – 41370 сум. Ихтыяҗ иң зур булган һөнәрләр исемлегендә өченче урында – табиблар. Аларга 741 эш урыны бар. Уртача хезмәт хакы – 41319 сум. Алардан тыш, иң күп вакансия булган һөнәрләр арасында шәфкать туташлары, электр-газ белән эретеп ябыштыручылар, штукатурчылар, арматурачылар, монтажчылар, ташчылар тора. Гомумән алганда, Татарстанда 35 мең эш урыны тәкъдим ителә. Ә рәсми рәвештә эшсез булып 6,3 мең кеше теркәлгән. Эльмира Зарипова әйтүенчә, 2030 елга кадәр республикада 173,1 мең эшче әзерләргә кирәк булачак.

Россия хәрбиләре ВСУның контрһөҗүме барышында каршы якның 13 меңнән артык кешесен һәм 250гә якын танкын юкка чыгарган. Бу хакта РФ Иминлек Советы секретаре Николай Патрушев әйткән.
Аның сүзләренә караганда, 4–21 июнь көннәрендә Россия хәрбиләре юкка чыгарган 246 танкның 13е Көнбатыш илләрендә ясалган. Моннан тыш ВСУның 595 (59) бронемашинасы, 279 (48) арттиллерия орудиесе һәм минометы сафтан чыгарылган.

Бу атна ахырында республикада һава температурасы 24 градустан күтәрелмәячәк. Киләсе атна башында исә синоптиклар җылырак көннәр вәгъдә итә.
Җомга – 23 июньдә төнлә 4–9, көндез 16–21 градус җылы вәгъдә итәләр. Урыны белән кыска вакытлы яңгыр яварга мөмкин. Шимбә көнне дә явым-төшем фаразлана. Температура төнлә 5–10, көндез 17–22 градус җылы булыр дип көтелә. 25 июньдә яңгыр яву ихтималы бар. Температура төнлә 6–11, көндез 19–24 градус җылы булыр дип фаразлана. Киләсе атна башында җылырак булачак, температура 20–26 градуска кадәр күтәрелергә мөмкин. Явым-төшем көтелми.

Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе сыйфатсыз товарлар яки мәҗбүриләп күрсәтелгән хезмәт өчен халыкка 75 миллион сум акчасын кире кайтарырга ярдәм иткән. Бу хакта идарә башлыгы Марина Патяшина Казанда узган конференциядә сөйләде.
«Безне ялган юридик оешмаларның күп булуы да борчый. Алар дәүләт органнарына шикаять язып биргән өчен зур суммада акча ала», – ди Марина Патяшина.
Идарә җитәкчесе сүзләренә караганда, сыйфатсыз товар сатучы һәм хезмәт күрсәтүчеләрдән еш кына яклаучысыз кешеләр зыян күрә. «Ел дәвамында аз керемле кешеләр һәм пенсионерлардан 2 мең чамасы мөрәҗәгать кабул иттек. Узган ел гына судларда 1,5 мең чамасы утырышта катнаштык. Зыян күрүчеләргә 75 миллион сум акчасын кайтарырга ярдәм иттек. Әмма намуссыз кешеләр алдауның яңа, тагын да хәйләкәррәк ысулларын таба», – ди Марина Патяшина.

tatarstan.ru

КАНАТЛЫ ЭШ

Тагын ике елдан Казанда елына 10 «Ту-214» очкычы ясый башларга ниятлиләр. Татарстан башкаласына эш сәфәре белән килгән Россия Премьер-министры Михаил Мишустин әнә шундый бурыч куйды. Очкычларны күпләп җитештерүне җайга салу өчен дәүләт 41,8 миллиард сум акча да бирәчәк. Ил Хөкүмәте җитәкчесе Казанга сөенечле яңалык белән килгән.

Казанга эш сәфәре кысасында Михаил Мишустин «Туполев» ГАҖ филиалы – Горбунов исемендәге Казан авиация заводына барды. Аны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов озатып йөрде. Ил Премьер-министры заводта сәнәгать мәйданын яңарту һәм техник яктан яңадан җиһазландыру программасының үтәлеше белән танышты. Бүген биредә «Ту-116», «Ту-214» очкычларын ясау, «Ту-116», «Ту-22М3» очкычларын төзекләндерү һәм камилләштерү белән шөгыльләнәләр. Михаил Мишустинга сәнәгать мәйданнарын да күрсәттеләр. Ул, шул исәптән, лазер ярдәмендә эретеп ябыштыру, титаннан ясалган зур детальләрне яндыру җиһазларын карады. Соңгы елларда әлеге җиһазларны тулысынча яңарткаННАР. «Бу – энергия кулланучыгына да өч тапкыр киметергә ярдәм итте», – дип сөйләде завод директоры урынбасары Борис Найшулер. Михаил Мишустин эшчеләрдән станокларның ышанычлылыгы турында да кызыксынды һәм уңай җавап алды.

– «Ту-214»не серияле җитештерүне җайга салу мөһим, – дип белдерде Россия Хөкүмәте җитәкчесе заводта узган тармакны үстерүгә багышланган киңәшмәдә. – Без 2025 елдан елына 10 очкыч җитештерә башларга тиеш. Казан авиация заводы әлеге бурычны үти алачак дип ышанам. Моның өчен ил Хөкүмәтеннән 41,8 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк. Россия Президенты Владимир Путин бу көннәрдә генә әнә шундый карар кабул итте. Әлеге акча шул исәптән заводны технологик яңарту, бинаЛАР төзү һәм төзекләндерүгә тотылачак.

Михаил Мишустин сүзләренә караганда, «Ту-214»нең ышанычлы булуы шик уятмый. Бу хакта очучылар үзләре үк әйтә икән. Өстәвенә очкычны ясаганда үзебезнең ил технологияләре кулланыла, димәк, ул Көнбатыш санкцияләренә бәйле түгел, дип тә ассызыкладылар киңәшмәдә. Очкыч 210 пассажирга исәпләнгән. Әллә хәрби-оборона комплексы тармагы предприятиесе булгангамы, заводның матбугат хезмәте төгәл саннарны әйтергә теләмичә: «Хәзерге вакытта Казан заводында дәүләт һәм коммерцияле заказлар буенча берничә лайнер җыела», – дип кенә чикләнде.

Аның каравы киләчәккә эш билгеле. Михаил Мишустин елына 10 очкыч җитештерү белән генә чикләнеп калмыйча, 2027 елда әлеге күрсәткечне 20гә кадәр җиткерергә кирәк, дип белдерде. Хөкүмәт җитәкчесе сүзләренә караганда, без очкычларны күпләп җитештерүне генә җайга салмыйбыз, ә тулы бер цикл төзеячәкбез. Бу җәһәттән ул тармакны кадрлар белән тәэмин итү турында да искә алды. Сүз уңаеннан, утырышка кадәр Михаил Мишустин завод эшчеләре белән очрашты. Сөйләшү барышында ил Хөкүмәте җитәкчесеннән эшче кадрларга кызыксынуны арттыру юллары турында сорадылар. Михаил Мишустин заводта эшләүче инженер, технолог кебек һөнәр ияләрен «иңиң»нәр дип атады.

– Бүген мондый белгечләргә кытлык зур, ә менә әлеге һөнәр белән кызыксынучылар аз, – диде ул киңәшмәдә.

Бу юнәлештә мәктәп эскәмиясе, гаиләдә үк эшләргә кирәклеген дә искәртте. Эшчеләр Премьер-министрдан оборона предприятиеләрендә эшләүчеләрне торак белән тәэмин итү турында сорады.

Очрашу

Заводтагы киңәшмә алдыннан Михаил Мишустин һәм Рөстәм Миңнеханов Казанның Җиңү паркында Мәңгелек ут янына чәчәкләр салдылар. Ә киңәшмә тәмамлангач, Россия Премьер-министры һәм Татарстан Рәисе аерым очрашу уздырдылар.

Рөстәм Миңнеханов бүгенге чаранның предприятие өчен зур әһәмияткә ия булуын әйтте. Республика алдында куелган яңа бурыч – очкычларны күпләп җитештерүне җайга салу эшен башкарып чыгарга да сүз бирде.

«Моңарчы күрелмәгән санкцияләргә карамастан, республика сәнәгате үсешен дәвам итә», – диде Татарстан Рәисе. Ул Премьер-министрга 2023 елның гыйнвар – май йомгаклары буенча республиканың социаль-икътисадый үсеше турында сөйләде. Республиканың тулай төбәк продукты бәяләүләр буенча 1,4 триллион сум тәшкил иткән, төяп җибәрелгән продукция күләме – 1,7 триллион сум, беренче кварталда инвестицияләр 156 миллиард сумга якын җәлеп ителгән, ә төзелеш эшләре күләме 161 миллиард сум тәшкил иткән. «Барлык күрсәткечләргә дә алдагы елларда формалашкан ныклык запасы һәм оператив кризиска каршы чаралар ярдәмендә ирешелде», – диде Рөстәм Миңнеханов һәм Президент Владимир Путинга, шәхсән Михаил Мишустинга, Россия Хөкүмәтенә үз вакытында ярдәм күрсәткән өчен рәхмәт әйтте. 2022 елда республиканың сәнәгать предприятиеләренә 70 миллиард сумлык ярдәм күрсәтелгән. Шул ук вакытта, санкцияләр икътисадка йогынты ясавын дәвам итә. Рөстәм Миңнеханов технологик суверенитетка ирешүнең мөһимлеген әйтте. «Без эре инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итәбез, яңа җитештерүләрне үстерәбез», – диде ул.

Хөкүмәт Рәисе социаль инфраструктура булдыруның мөһимлеген билгеләп үтте. Моннан тыш, Татарстанда технологик суверенитет мәсьәләләрендә эшнең югары дәрәҗәдә оештырылуын әйтте.

– Заводның бай тарихы бар. Традицияләрне саклап калып, яңа идеяләрне тормышка ашыру мөһим, – диде Михаил Мишустин. – Торак мәсьәләсенә килгәндә, бүген дәүләт тарафыннан аренда торагы бәясенең яртысына кадәр субсидияләү каралган. Башка төр ярдәм чаралары да гамәлдә. Бу юнәлештә тагын нәрсә эшләргә мөмкин икәнен карап тикшерәчәкбез.

Заводта ил Хөкүмәте җитәкчесе әзер «Ту-214»кә утырып та карады. «Boeing» бер читтә торсын», – диде Рөстәм Миңнеханов урындыклар арасыннан барганда, Россия Премьер-министры килешүен белдереп елмаеп куйды.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Ишекләр ачылды

Казан табиблары өчен истәлекле ике вакыйга булды. Дәрвишләр бистәсендә 6 нчы балалар поликлиникасының филиалын ачтылар, ә Алексей Казем-Бек урамында урнашкан йортта 30 медицина белгече яңа фатирлы булды. Тантаналарда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко катнашты.

Балалар поликлиникасы филиалы торак массив эчендә төзелгән, анда кешегә уңайлы булсын өчен барлык шартлар тудырылган. Поликлиника 11,5 мең балага хезмәт күрсәтәчәк. Медицина учреждениесендә иң заманча җиһазлар урнаштырылган. «Бу – республикада федераль коллегаларыбыз белән бергә тормышка ашырылган объектларның берсе. Алар шактый күп. Без Президент Владимир Путинга һәм Хөкүмәт Рәисе Михаил Мишустинга рәхмәтле», – диде Татарстан Рәисе. «Балалар сәламәтлегенә мондый игътибар бирелү бик яхшы. Һәр атна балаларга ярдәм күрсәтүче яңа медицина оешмалары – терновкәләндерү үзәкләре, стационарлар, ә бүген поликлиника ачыла», – диде Михаил Мурашко. Министр сүзләренә караганда, илдә балаларга ярдәм күрсәтү эше яхшырды.

М-14 микрорайонында урнашкан йорт исә социаль ипотека программасы буенча төзелгән. 30 фатирны медицина хезмәткәрләренә тапшырдылар. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, микрорайонда уңайлы тормыш өчен кирәкле шартлар тудырылган. «Бу мәйданчык безнең медицина учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Географик, экологик һәм башка барлык параметрлар буенча бу зона яшәү өчен бик уңайлы», – диде ул һәм республика медицина хезмәткәрләренең торак шартларын яхшырту эше дәвам итәсен әйтте. Михаил Мурашко ассызыклаганча, Татарстанда медицина тармагына яшь белгечләрне җәлеп итү өчен шартлар тудыралар. «Мин монда табибларны хөрмәт итүләренә бик шатмын», – диде министр. Аннары кунаклар Малыхиннар гаиләсенең яңа фатирын карады.

АВЫЛ БАЛАСЫНА КАРАГЫЗ!

Сан

Татарстанда яшьләр төркеменә караучы (14–35 яшь аралыгындагы) **1 млн 72 мең** кеше яши.

tatarstan.ru

Балаларны ватанпәрвәр итеп тәрбияләү өчен нишләргә кирәк? Нәрсә эшләп җиткермибез? Рухи кыйммәтләр турында саннар телендә сөйләшү дөресме? Бу сорауларга җавапны Татарстан Дәүләт Советы президиумының Питрәч районында узган утырышында эзләдек. Күчмә утырыш Хәтер һәм кайгы көнендә Яңа Шигали авылында Советлар Союзы Герое Галимҗан Камалиев исемендәге лицейда узды.

Утырыш алдыннан депутатлар һәм президиум әгъзалары Советлар Союзы Герое Галимҗан Камалиев бюстына чәчәкләр салды, Хәтер һәм кайгы көненә багышланган митингта катнашты. Ватанпәрвәрлек турында анда башланган сүз утырышта дәвам итте. Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков республикада яшәүче миллионнан артык яшь буын вәкиленә патриотик тәрбия бирүнең төрле ысулларына тукталды. Аерым алганда, «Татарстан Республикасында яшьләргә патриотик тәрбия бирү» атамалы программасының ни рәвешле гамәлгә ашырылуы турында сөйләде. Моннан тыш, министр хәрби-патриотик тәрбия өлкәсендә уздырылган чараларга да аерым тукталды. Әйтик, «Аҗаган» уены, «Әлбадән» фестивале турында һәркайсыбыз ишетеп булса да беләә инде. Ләкин Татарстанда алардан тыш та чаралар шактый.

– Ләкин патриотик тәрбияне хәрби юнәлештә генә карарга кирәкми. Әйтик, яшьләр күп вакытларын интернетта уздыра. Ә анда яхшы хәбәрләргә караганда начарлары күбрәк. Гадиләштереп әйткәндә, интернетта яки массакүләм мәгълүмат чараларында яшь буын вәкиле турында сөйләсеннәр өчен, аның белән нинди дә булса начар хәл килеп чыгарга тиеш. Безгә яшь галимнәребез, белгечләребез турында күбрәк сөйләшергә кирәк. Яшьләрнең көндәлек тормышында үрнәк образлар күбрәк булырга тиеш, – дип сөйләде Ринат Садыйков.

Аңлашыла инде, яшь буынга патриотик тәрбия бирү бер генә министрлыкның бурычы түгел. Ринат Садыйков сүзләре белән әйтсәк, бу әһәмиятле эшне берләшеп, билгеле бер системага салып башкарырга кирәк.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы да балаларны һәм яшьләрне ватанпәрвәр итеп тәрбияләүгә игътибарын кызганмый. Министр урынбасары Алсу Әсадуллина да моны республикада уздырыла торган вакыйга һәм чараларны барлап раслады. Бу өлкәдә туган телләргә багышланган чараларның әһәмиятле булуын искәртте.

Билгеле, балалар һәм яшьләр өчен кызыклы чараларның төрле һәм күп булуы – бик шәп нәрсә, ләкин сыйфат мәсьәләсе барыбер әһәмиятлерәк. Бу хакта Фәрит Мөхәммәтшин да әйтте, чыгыш ясаучыларга патриотик тәрбия юнәлешендәге кимчелекләр турында да сөйләргә кушты. Җыелышып сөйләшүнең нәтиҗәсе дә булырга тиеш бит. Әмма бу юлы әзерләнгән чыгышларда барыбер дә саннар өстенлек итте.

– Сез чараларда катнашучыларны, үсмерләр клубларында, берләшмәләрдә исәпләнүчеләрне санышсыз. Ә саналмыйча калганнар кайда? Нишли алар? Нигә бүген алар турында сүз булмады? – дип сузен тәнкыйтьтән башлады парламент Рәисе. – Бүгенге шартларда патриотик тәрбия мәсьәләсе алгы планда булырга тиеш. Яшьләребезгә басым бик көчле. Аларның әле формалашып бетмәгән аңнарыннан файдаланырга теләүчеләр бик күп.

Фәрит Мөхәммәтшин тәрбия өлкәсендә авыл балаларын мисал итеп китерде.

– Нәкъ менә авылда, авылда яшәүче гаиләләрдә телебез, гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз, традицион кыйммәтләребез чын мәгънәсендә саклана. Шул мохиттә, шундый тәрбиядә үскән балаларга күз салыгыз! Ватанпәрвәрлек гаиләдән башлана, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Белдерү

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең сайланулы органнары депутатларын өстәмә сайлау турында хәбәр итә. Сайлау 2023 елның 10 сентябренә билгеләнгән.
Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең сайланулы органнары депутатларын өстәмә сайлауда катнашырга хокуклы сәяси партияләр һәм сәяси партияләрнең төбәк бүлекләре, гомумроссия иҗтимагый берләшмәләр, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләре һәм җирле иҗтимагый берләшмәләр турында мәгълүмат Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-коммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырылган: https://to16.minjust.gov.ru/ru/pages/vybory-v-rossijskoj-federacii/.

АКЧА ҖИЛӘГЕ

Шөгыль

Җиләкне һәркем ярата. Әмма аны җыю өчен сабырлык та, вакыт та кирәк. Шуңа күрә, алучысы булгач, сатучысы да табыла. Җиләк җыеп, бер айда 200–300әр мең сум акча эшләүчеләр бар. Ходай биргән нигъмәт җыеп балаларын укыталар, кредитларын түлиләр, ялга баралар.

Мамадыш якларында яшәүчеләр төн йокысын да, ашавын да онытып акча эшли. Араларында гаиләләре белән көненә 50шәр мең сум акча эшләүчеләр дә бар. Армый да, талмый да алар. «Җиләк вакыты бер генә», – ди үзләре. Быел алар бу эшкә июнь башында ук тотындылар. Мамадышта яшәүче Наталья Фатыйхова әйтүенчә, баштарак каен җиләгенең 1 литрын 1500 сумнан биргәннәр. «Кеше җыя башлагач, бәяне төшерергә туры килде. Булганына шөкер. Быел 250 мең сум акча эшләргә өлгердек инде», – ди ул.

Әмма быел җиләк күп түгел.

– Урман эчендә каен җиләген табарга була әле. Кодагыйларым көн саен 50 литрга якын җиләк җыя. Сөйләгәндә генә җиңел. Җиләк җыю зур сабырлык сорый, – ди Түбән Яке авылында яшәүче Миннекамал Гасыймова. – Без җиләкне заказга гына җыябыз. Юл буена чыгып яки Казан – Чаллы юлындагы Сайкичү базарына барып сатсаң, бәясе төшә. Кайбер көнне анда бер литрын 700–800 сумга да бирүчеләр бар.

Ранилә Исмәгыйлова әбисе Минзифа белән көн саен 11 литр каен җиләге җыеп кайта икән. Беренче курсны тәмамлаган студент кыз шул рәвешле акча эшли. Инде ун көнләп сатканнар. Икесенә 110 мең сум акча эшләргә өлгергәннәр. Тиздән җир җиләгенә тотынмакчылар. Үзләре генә белгән урыннары бар икән. «Безнең якларда җиләкчеләр үз «оялыгы»н сиздермәскә тырыша. Кайчак, артыңнан барып, эзеңә төшүчеләр дә бар. Әгәр бүген авызыңнан ычкына икән, иртәгә җиләксез каласың, – ди Миңнегөл Юнысова. – Гаилә белән җыйсаң, файдасы зур. Бергәләп эшли торган эш инде ул. Машинаң булу да кирәк. Башта бер бәягә сатсак, хезер хакы әкренләп төшә инде. Кемдер каен җиләгенең 1 литрын 1500 сумга бирә, кемдер 800 сумга сата».

Чаллыда яшәүче Искәндәровлар гаиләсе дә җиләк сезонын көтеп ала. Һәр елны җиң сызганып эшлиләр дә шул акчага ял итәргә баралар.

– Әтием дә, әнием дә кечкенәдән җиләк җыеп үскән. Без дә алардан күреп, кечкенәдән җиләк җыя башладык. Һәр елны гаиләбез белән диңгез буена барырлык акча эшлибез. Җиләкне бик яратып җыябыз. Кайберәүләр: «Нигә балагызны интектерәсез?» – дип аптырый. Ничек инде бер айлык сезонда акча эшләмисең?! Аллаһы Тәгалә биргән җимешне ничек җыймаска кирәк?! Кечкенәрәк чакта җиләк акчасына мәктәп кирәк-яраклары ала идек. Телефон алганым да булды. Бу бит – горурлык! Акчаның тәмен дә, кадерен дә белергә өйрәтә җиләк җыю, – ди Алинә.

13 яшьлек Данил Әхмәтгалиев та 10 яшеннән җиләк җыя.

– Башта бу эшне яратмый идем. Аннары остарып киттем. Тиз-тиз җыярга да өйрәндем. Әбием сатып бирә. Чиләктәге җиләкләрне 1 литрлы савытларга бүлеп сатабыз. Алай эшләсәң, акчасы күп чыга. Чиләге 2500 сумга төшә, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БЫЕЛ МАМАДЫШ ЯКЛАРЫНДА ҖИЛӘК БӘЯЛӘРЕ

Каен җиләгенең 1 литрлы чиләге – **1000–1200**,
5лесе – **4000–6000 сум**.
Җир җиләгенең 1 литрлы чиләге – **500**,
5лесе – **1500–2000 сум**.
Чистартылган җир җиләгенең 5 литрлы чиләге – **4500–5000 сум**.

Әйтеп кенә бактым

Гадәт

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Риман дус, 30 ел бергә яшәгән хатыннан зарлану бик килешми инде. Ну, соңгы вакытларда, пенсиягә чыккач, дип әйтүем, тәмам бозылды ул. Ни өчен сиңа сөйлим? Синең хатын да дәүләт хезмәтендә эшләде бит, минеке дә. Дәүләт хезмәте аны да бозмады микән, дип әйтү генә инде бу. Үпкәли күрмә, яме!

Күптәнге танышымның шулай дип шалтыратуы бик сәер тоелды. Юкса алар хатыны белән, ул үзе әйтмешли, «душа в душу» яшәделәр. Нәрсә булган боларга, «душа»лары нишләгән? Хатынының «тәмам бозылуы» нидән гыйбарәт? Ире телефоннан берәрсе белән сөйләшә башласа, янына йөгереп килеп, ни турында сөйләшкәннәрен тыңлый икән. Телефон шалтыраса, иң элек: «Кем ул, нинди кеше?» – дип төпченә башлый икән. Шуннан соң боларның сөйләшкәннәрен ахырына хәтле тыңлап бетерә дә: «Ник тегене әйттең, ник болай дидең?» – дип бәйләнә башлый ди.

– Кыскасы, мин хәзер «под колпаком» яшим, – диде танышым.

Мин аны аңлыйм шикелле. Гомер буе хакимият органнарында эшләүчеләр ниндидер язылмаган законнар кысасында яшиләр. Аларга артык ачылып китеп сөйләргә ярамый, кирәкмәгән сүз әйтеп ташлавың бар. Сер саклый белү аларда гадәткә әйләнгән. Бу гадәт хакимият вертикале тирәсендәге һәркемгә хас.

Бер елны үпкәгә салкын тидереп хастаханәдә яттым. Дүрт кешелек палатада сәламәтлегебез, дөнья хәлләре турында сөйләшеп ятабыз. Күрше караватта ятучы Рәдиф дигән егет миңа бик сәер тоелды. Нәрсәдер әйтер алдыннан караватыннан тора да палата буйлап йөреп килә, бәдрәф ишеген дә ачып карый, аннан соң як-ягына ялт-йолт карана-карана, сүз башлый бу. Янәсе, берәрсе тыңлап тормыймы? Юкса ярамаган нәрсә дә сөйләми, ну нәрсәдәндер шикләнгән кебек.

– Рәдиф, – мәйтәм, – палатада чит кеше юк, без дүртәү генә бит, кемнән куркасың?

– Курыкмыйм, на всякий случай… – ди бу. Әле тизтиз атлап барып, палата ишеген дә ачып карый, ишекнең теге ягында берәрсе тыңлап тормый микән дип уйлый, күрәсең. Соңрак белдек: Рәдиф шофер икән, ниндидер бер зур түрәне йөртә. Димәк, автомат рәвештә дигәндәй, түрәләр белән «бер обойма»да булып чыга. Аны гаепләп язу түгел инде бу. Түрәләр бакчасына да таш атасы килми. Хакимият халыктан ерагайды, дигән сүзләр шактый еш ишетелсә дә, кайвакыт түрәләрне кызганып та куям. Ни гаҗәп, горурланып та алам. Ни дисәң дә, халыкның яшәеше, язмышына бәйле мәсьәләләрне түрәләр хәл итә. Әлеге мәсьәләләрне хәл иткәндә, алар төрле кыенлыкларга да очрыйдыр, җәмгыять алдында торган көндәлезлекләр турында ачыктан-ачык сөйләп, халыкның тынычлыгын аласылары килмидер. Бәлки, алар эшкә керешкәнче дәүләт серен саклау турында ант та бирәләрдер әле, бу турыда, бәлки, берәр документка кул да куялардыр… Шулай вәсвәсәләнеп утырдым да дәүләт хезмәтендәге бер дуска шалтыраттым: «Сезгә шундый-шундый таләпләр бармы?» – дидем.

Рәсми рәвештә цензура да юк, бернинди документка кул да куйдырмыйлар икән. Әмма «авызыңни әйткәнне колагың ишетсен»не һәр хезмәткәр белә. «Авызны чама белән ачу» гадәте еллар буе формалашып, язылмаган закон көчен ала, түрәләр пенсия яшенә дә шул закон белән килеп керә. «Чир китә, гадәт китми», – диләр үзе, әмма түрәләрнең сер саклау гадәте кайчак чиргә әйләнеп, аларны гомер буе эзәрлекли, күрәсең. Миңа телефоннан шалтыраткан күптәнге танышыма бу хакта әйтмәдем инде, кәефен җибәрәсе килмәде. «Чирле хатын белән яшим икән», – дип үз-үзен битәрләмәсен. Ә бит, бер уйлаганда, теләңә ни килсә – шуны сөйләп йөрү зыянлырак та әле. Тел кечкенә булса да, кайчак сүзең дөньяга сыймаска мөмкин. Халык нәрсә ди әле? «Аз сүз – алтын, күп сүз – бакыр», – ди. Менә вәйт!

КАПИЦА ФОРМУЛАСЫ

СӘНГАТЬНЕҢ АСТЫ ӨСКӘ ӘЙЛӘНГӘНДӘ

Берничә көн элек кенә «Россия» авиакомпаниясенең очышлар белән идарә итү үзәге директоры 58 яшьлек Андрей Перетны телефон алдакчылары 12 миллион сумга кәкре каенга терәттеләр. Катлаулы булмаган һәм тапталып беткән схема ярдәмендә.

Андрей Перетка билгесез бер кеше шалтырата һәм үзен полиция капитаны дип таныштыра. «Капитан» соңгы вакытларда мошенниклык очраклары күп булуын искәртә. Зур компания директорының банк счетларында акчалары бар икән, хәзер аңа Үзәк банктан шалтыратып, шул акчаларны ничек итеп мошенниклардан саклап калырга өйрәтәчәкләрен әйтә. Чынлап та, озак та тормый, 58 яшьлек сакаллы сабыйга бер кыз шалтырата һәм аның исеменнән 12 миллион сумлык кредитка гаризалар керүен әйтә. Мошенниклар шулай эшли, дип шик сала. Алардан котылуның бер генә юлы бар икән: үзең шул суммага кредит алып, «куркынычсыз» счетка салып кую. Теләсә кайсы урта кул мәктәп укучысы эшнең нидә икәнлеген төшенер иде бу очракта, әмма… Перет кушканны берсүзсез үти. Акчаның кая киткәнен аңлыйсыздыр инде.

Әле күптән түгел генә бер чиновник хатын хәрби комиссариатка ут төртеп азапланды. Шул гамәлне уңышлы башкарса, мошенниклар аңа урланган акчасын кайтарып бирергә вәгъдә иткән. Телефон алдакчылары тарафыннан шәрә кармакка каптырылган мокытлар арасында зур банкларның вице-президентлары, аларның киңәшчеләре, Россиянең идарәче элитасының балалары бар. Владимир Путин сүзчесе Песков әфәнде моннан бер елга якын элек үз кызының ничек итеп телефон гипнозы тәэсирендә банк счетындагы акчаларын югалтуы хакында сөйләгән иде.

Укучылар көтмәсен: автор һич кенә дә мошенниклар кулланган ысуллар һәм аларга ничек каршы тору турында язарга җыенмый. Ни өчен без, XXI гасыр кешеләре, шулай җиңел генә алдана торган беркатлыларга әверелдек, шул хакта бергәләп фикер йөртергә өнди ул. Югары белеме булган үз эшенең профессионаллары (арада доцент-профессорлар да бар) бик җиңел алданалар бит. Берничә минутлык телефон сөйләшүендә шулай җиңел туарылгач һәм ыштансыз калырлык дәрәҗәдә бөлгә илтә торган гамәлләр кылгач, телевизор һәм интернет гипнозына ничек каршы торасың?! Ә бит миләр өчен, кешеләрнең рухын яулап алу өчен, Җир масштабында тарихта тиңсез көрәш бара һәм иң аяныч шул: бик уңышлы бара. Автор соңгы айларда югары белемле технарьлар, инженерлар, идарәнең югары һәм урта буынында эш йөрткән чиновниклар белән сөйләшә дә таң кала: балаларча беркатлылык, акның – ак, караның кара икәненә ышандырып булмау, ә менә киресенчә, караны ак дип күрсәтүнең бик җиңел булуы белән очраша.

Ни өчен кешеләр шулай кискен үзгәрде? Сорау борчу тудыра, чөнки кешелек җәмгыяте, гипнозга алданып, зур фаҗигагә таба атлый. 12 миллион сумны гына түгел, миллиардларны да түгел, алардан күпкә кыйммәтрәк булган рухын югалту алдында тора. Бу хакта атаклы физик, 1973 елдан башлап Үзәк телевидениедән «Ап-ачык – акылга сыймаслык («Очевидное – невероятное») тапшыруын алып барган Сергей Капица, ачынып һәм әрнеп: «Җәмгыять берни дә күрми, чөнки аны тирән гипноз халәтендә тоталар. Халык беркайчан да хәзерге кебек караңгы хәлдә булмады», – дип әйткән иде. Массаларның транс халәтендә яшәүләренең сәбәбен галим берсеннән-берсе томанарак булган бетмәс сериалларда, бозык-оятсыз эстрадада, әчке аңга тәэсир итә торган агрессив фильмнарда күрә. Капица 2012 елда үлде инде. Үзеннән соңгы унъеллыкта массакүләм һәм масштаблы психозның ни дәрәҗәгә җитүен күрә алса, кабереннән сикереп торыр иде, мөгаен. Асылда җәмгыять, гипнозланган куян кебек, буар елан авызына кереп бара.

Автор шушы урында якын киләчәкне фаразлаудан туктый һәм массакүләм сәнгатьнең безнең аңнарга ясаган агулы тәэсире турында сөйләшүгә күчә. Элекке совет кешеләре онытып ук бетермәгәндер: бездә кайчандыр китап культы бар иде. Юк, арзанлы детективлар, бозыклык маҗаралары сурәтләнгән романнар түгел, фәсәфи эчтәлекле классик әдәбият абруйлы булды. Технарьлар да, гуманитарийлар да, сыер савучылар һәм профессорлар да матур әдәбиятны ябырылып укыды. Дөнья масштабында да бар иде андый шаукым. Әхлаклы нәфис прозаның, фәлсәфи шигърияттнең үз бәяләүчеләре җитәрлек күп иде. Автор саннар китереп тормый. Бер генә нәрсәне искәртә: инженерлар һәм табиблар укып кына калмый, үзләре дә иҗат итә иде. Профессиональ иҗатка килеп танылу казанучылар арасында филологлар гына түгел, төрле профессия вәкилләре байтак булды. Әмма беркөнне кисәк кенә либераллык дигән идеология капитализм белән бергә ишекләрдән бәреп керде дә идеаллар бер мизгелдә алышынды: кичә генә матбугат бумы иде – ул туктады, матур әдәбият тиражлары уннарча һәм йөзләрчә тапкыр кимеде, артистлар сәхнәдә ниләр генә кыланмады. Чын сәнгатьне бәяләүчеләр бетте диярлек. Интернетка сылтамыйк, дөнья пәрәвезе юк иде әле ул елларда.

Кайчандыр чын әдәбиятны бәяләүчеләр хәтта Голливуд йолдызлары арасында да бар иде. Әле капиталистик дөнья либераллык сазлыгына хәзерге дәрәҗәдә үк төшеп батмаган чакта, мәшһүр немец һәм америкалы актриса, популяр җырчы Марлен Дитрих Мәскәүгә гастрольгә килә. 1964 ел, коммунизм юлбашчылары буржуаз сәнгать легендасына әверелгән хатыннан СССРда нәрсәне күрергә теләвен сорыйлар. Кремльгә алып барсыннармы, Мавзолейны күрсәтсеннәрме, Зур театрга кертсеннәрме, янәсе. «Мин Паустовский белән танышыр идем, – ди ул. – Бу – минем күптәнге хыялым». Язучының «Телеграмма» хикәясен укыганнан бирле, авторы белән күрешәсе килеп яшәгән икән. Авыру әдипне табып, дөнья йолдызы янына китерәләр һәм Марлен Дитрих аның алдына килеп тезләнә, кулыннан үбә, аны битенә тидерә, күзләреннән исә яшь ага. Хөрмәтле укучы, әгәр син бу тарихны белмәгән булсаң, «Телеграмма» хикәясенә реклама укыдым дип аңла. Анда бернинди кискен сюжет та, динамик вакыйгалар да юк, кеше җаны бар… Менә шундый әдәбият бәяләнә иде кайчандыр. Хәзер аның бәясе бик төште инде. Арзанлы сюжетлар мәйданга чыкты. Яхшы әдәби әсәр исә уйландыра да, хисләндерә дә. Акылга һәм йөрәккә шифалы тәэсир ясый. Хәер, хикәя укыдың да җиңел генә яхшы якка үзгәрдең дигән сүз түгел әле бу. Изгелеккә ирешү тырышлык таләп итә. Түбәнгә төшү генә җиңел ул, югары күтәрелү бик катлаулы. Әмма шулай да йоклаган намус уяна, вөҗдан, ваемсызлык сазлыгыннан чыгып, баш калкыта.

Болар барысы да максатчан рәвештә артка чигерелде. Бу язманы әзерләү алдыннан мин хәзерге заманның иң популяр рәссамнары иҗаты белән кыскача гына таныштым. Георг Базелиц дигән атаклы немец рәссамы бар икән, мәсәлән. Картиналары бик югары бәяләнә. Аны неоэкспрессионизм остасы дип тә атыйлар. Беләм инде: укучыларның күбесе «экспрессионизм», «модернизм» дигән терминнар белән бик үк таныш түгел. Сәнгатькә тилерү элементы килеп керү дип аңлатыр идем мин аларның асылын. Алларына нео-, пост- дигән алкушымча өстәлсә, тилерү масштабы берничә тапкыр артуны аңлата. Базелиц картиналарын гади авыл кешесенә күрсәтсәң, балта белән юныл ясалган дигән бәя бирер иде. Әмма аның сәнгатенең «бөек»леге анда гына түгел. Аның картиналары асны өскә әйләндереп ясалган, бөтен кыйммәте шунда һәм әхлаксызлыкта. Марлен Детрих СССРга килгән елларда Базелицның картиналары Көнбатышта да әхлаксызлыкта гаепләнеп тыела, аны хәтта судка бирәләр. Хәзер ул – иҗаты югары бәяләнүче авторларның берсе. Яхшы итеп рекламаланса, хәзер рәссам пумаласыннан төшеп калган тапны да бөек картина дип миллионлаган долларга сатып була. Элекке совет кешеләренең генә түгел, Көнбатыш массаларының да әхлагы, сәнгатьне аңлавы-бәяләве шулай үзгәрде. Җәмгыять, аркылы-торкылы сызыкларга мөкиббән китеп, күргәзмәләргә йөри икән, димәк, анда акылның яралгысы да калмаган дигән сүз. Гафу итегез, интеллект бар – акыл юк. Шулай булгач, язма башында искә алынган Андрей Перет дигән әфәнденең телефон алдакчыларына 12 миллион сум кредит алып бирүенә гаҗәпләнмик инде. Очышлар белән бик әйбәт идарә итә торгандыр ул, бәлки, әмма банктагы акчасы белән идарә итә алмый. Хәзерге дөньядан акылның, юылып, чүплеккә ташлануына байтак мисаллар әзерләгән идем, әмма газета мәйданы чикләнгән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Эльвира ВӘЛИЕВА

ӘЙЛӘНЕЧТӘН ТИЗРӘК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Су уртасындагы «генерал»

«Кран астында йөрмәскә, елга ярына якын килмәскә, баштагы касканы салмаска...» Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы төзелешен үз күзләре белән күрергә дип килгән журналистларга автобустан төшүгә үк куркынычсызлык «дәрес»е укыттылар. Төзелеш мәйданында саклык чараларын бик төгәл үтиләр. Юлчымы син, журналистмы – һәркемнең өстендә төзүчеләрнең ерактан ук «кычкырып» торучы сары жилеты, башта каска булырга тиеш. Әллә ияләшмәгәнгәме, бер-ике сәгатьтән баш өстендә таҗ кебек утырып торган касканы салып атасы килә башлады. Көн буе шулай йөргән төзүчеләрнең башы ничек чыдыйдыр.

Казан – Екатеринбург югары тизлекле трассасы кысасында Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы төзелеше өчкә бүленгән. Аның беренче өлешендә Чулман елгасы аша озынлыгы 1,3 чакрым (шуның 800 метры су өстеннән узачак. – **Ред.**) тәшкил иткән күпер салалар. Биредә техник хәрәкәт киләсе ел ахырында ук ачылачак. Алга китеп булса да әйтик, әйләнеч юл төзелеше барышында барлыгы 10 күпер, 11 юлүткәргеч, 5 транспорт-юл чишелеше һәм шулкадәр үк юл киселеше төзеячәкләр. Чулман аша күпернең бәясе – 23 миллиард сум. Аның аша тәүлегенә 25 меңгә кадәр машина уза алачак дип көтелә. Әлегә исә төзелеш мәйданында эш кайный.

– Эш алдан фаразланганнан тизрәк тә бара, – дип сөйләде төзелеш өчен җаваплы «Федераль юл агентлыгының Идел – Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» оешмасы җитәкчесе урынбасары Тимур Хафизов. – Күпер барлыгы 22 баганадан торачак. Шул исәптән 7 терәк суга утыртылачак. Коры җирдәге баганалар әзер диярлек инде. Бүген елга уртасындагы җиде баганаың алтысында эш алып барыла. Әлегә күпергә исем уйлап тапмадык.

Чулман күпере төзелешендә 400гә якын кеше, 60лап техника эшли. Шунысын да әйтергә кирәк: аларның күбесе – Кырым күперен салуда катнашучылар. Су уртасында күпер баганалары ничек «үсеп» чыга икәнен дә күрсәттеләр. Шакатудан баш кашырсың, билләһи. Елга төбен тикшергәннән соң, тиешле урынга субай кагалар, аннары исә бу мәйданны тимер баганалар белән колачлап алып, судан корыталар һәм әзер фундаментта багана күтәрәләр. Төзүчеләр үзләре суга утыртыла торган терәкләрне «генераллар» дип атый икән. Алар чыннан да коры җирдәге конструкцияләрдән зурлыгы ягыннан шактый аерыла. Күз алдына китерегез: елгадан «үсеп» чыккан баганаың суга тиеп торган нигезе (ә ул аның иң саллы өлеше) 29га 7 метрны тәшкил итә. Шундый бер багана күтәрү өчен генә дә төзүчеләр аның тирәюненә 30дан артык бораулы субай утырта.

11 мең тонна тимер

«Юллар һәм күперләр» АҖ филиалының проект җитәкчесе урынбасары Марс Юлтыев сүзләренә караганда, яңа төзелүче күпернең төп үзенчәлеге дә суга утыртылучы баганаларга бәйле. Эш шунда ки, күпернең бер як яры – тигез җиргә (Түбән Кама районының Корабельная урманы), ә икенче ягы биек тау битенә (Алабуга районы) туры килә. Шуңа күрә төзелеш барышында баганалар гына түгел, юл үзе дә югарыга таба «үсеп» бара. Елганың бер ярындагы баганаларның озынлыгы 8 метр булса, каршы якта алар биш тапкыр диярлек озынрак булачак. Өстәвенә елга агымында эшлисе. Сүз уңаеннан, бу урында Чулманның тирәнлеге 22 метрга кадәр җитә.

– Кагыйдәләр нигезендә мондый күперләрне салу вакыты өч ел ярым тәшкил итә (Чулман елгасында эшкә узган елның сентябрь азагында керешкәннәр. – **Ред.**). Без төзелешне мөмкин кадәр тизләтергә тырышабыз, – ди Тимур Хафизов.

ТҮБӘН КАМА ҺӘМ ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЛӘРЕН УРАП УЗУ ЮЛЫ

М7 трассасыннан барганда Алабуга районындагы Костенеевка авылы янәшәсендә борылып, Чулман күпере аша Түбән Кама ягына чыга. Алга таба Зәй, Тукай районнары аша узып, Сосновый Бор бистәсенә җиткәнче кабат М7 трассасына тоташа. Әлеге юл Казан ягыннан Түбән Кама, Зәй, Тукай, Минзәлә, Актаныш һәм шул яктагы башка районнарга йөрүчеләрнең вакытын янга калдырачак.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Күпер төзелешендә үзебездә җитештерелүче материаллар гына кулланыла. Мәсәлән, тимер конструкцияләрне Белгородтан алып кайталар, ком һәм бетон – Түбән Каманыкы.

Чулман күпере төзелешенең яңалыклары да бар. Мәсәлән, эшне тизләтү өчен, биредә бер үк вакытта ике субай кагу технологиясен кулланалар.

– Якын арада төзелеш мәйданына йөзмә бетон заводы да киләчәк. Моңарчы мондый алымны кулланган юк иде әле. Болай эшләгәндә ярдан бетон катнашмасы ташыйсы булмаячак, димәк, вакыт та янга калачак, – дип аңлатты Марс Юлтыев.

Йөзеп йөри торган завод нинди була соң ул, дип төпченә башлагач, серне чиштеләр. Баксаң, әзер баржага бетон җитештерү өчен тиешле җиһазлар урнаштыралар икән. Менә сиңа – завод!

Баганалар утырту белән берррәттән, биредә күпер торыкларын төзүгә дә керешкәннәр инде. Монысы ни тагын дип аптырамагыз. Бу – күпер терәкләрен тоташтыручы тимер аралыклар, булачак юл, кыскасы. Аны балаларның «Лего» уены кебек, аерым кисәкләрдән җыялар.

– Күпер төзү өчен 11 мең тоннага якын металл конструкция кирәк булачак, – ди Тимур Хафизов. – Бүген шуның 600 тоннага якыны кайтты инде. Күпер торыклары өлешләп җыела. Төзүчеләр авырлыгы – 82 тонна, озынлыгы 12 метр тәшкил итүче тәүге аралыкны җыя башлады. Барлыгы шундый 130 блок кирәк булачак. Металл конструкцияләр Чулман күпере өчен махсус эшләнде.

Булачак юлның бер өлешен җирдә җыя башлыйлар да, аннары күпер өстендәге махсус мәйданчыкка күтәреп, эшне дәвам иттерәләр. Шуннан соң озынлыгы 15 метрга кадәр җиткән аралыкны күпернең бер ягыннан икенче ягына этәчәкләр. Бу эшкә август ахырында керешергә ниятлиләр. Әнә шулай итеп тоташ бер күпер барлыкка киләчәк.

Көтәсе күп калмады

Озынлыгы ягыннан икенче урында торучы күпер Аулаш елгасы аша төзелә. Биредә ярты эшне тәмамлаганнар. Башка күперләрдән аермалы буларак, монысының астыннан тимер юл да уза.

– Шуңа күрә биредә аеруча да сак булырга туры килә, – ди Идел – Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсенең Чаллыдагы юл хуҗалыгы баш белгече Юрий Крашенинников. – Тимер юлга кадәр булган металл конструкцияләрне җыеп бетердек. Ә поездлар өстендә исә тимер юлчылар рөхсәт иткән вакытта гына эшләргә туры килә. Торыкларны августта җыеп бетерәчәкбез.

Ел азагына кадәр әйләнеч юлның 70 процентына таш түшәп бетерергә телиләр. Әлегә исә төзелешнең икенче өлешенә керүче юлларның 13 чакрымына асфальт җәелгән. Өченче өлешкә керүче юлларда бу күрсәткеч азрак, ә беренче өлештә таш юл гомумән юк әле.

Фикер

Илдар МИНҺАҖЕВ,
Федераль юл агентлыгының Идел – Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе җитәкчесе:
– Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы, төзелеп беткәннән соң, «Көнбатыш – Көнчыгыш» маршруты составына керәчәк. Әлеге глобаль проектны тормышка ашыру бәрабәренә Түбән Кама сәнәгатьчеләренә һәм шәһәр халкына илебезнең төп транспорт артерияләренә юл ачылачак. Шулай ук М7 «Волга» трассасының Чаллы шәһәре аша узучы өлеше бушаячак.

– Яңа юлның калынлыгы 1 метр чамасы тәшкил итә, – дип сөйләде «Алексеевскдорстрой»ның икенче участок җитәкчесе Сергей Ещёв. – Асфальт-бетон заводында сәгатенә 240 тонна катнашма җитештерелә. Чималга кытлык юк. Безнең юллар, ул-бу була калса, хәрби очкычларга төшү һәм очып китү полосасы буларак та хезмәт итә алачак.

Юл тузансыз булмас

– Яңа юл ачылганны түземсезлек белән көтәбез, – ди егерме елга якын йөк ташу машинасын йөртүче Дамир Насыйбуллин. – Чаллы – Түбән Кама – «Алабуга» махсус икътисадый зонасы арасында еш йөрергә туры килә. Шәһәр эчендәге «бөке»ләрдән гарык мин. Башкача да булмый. Әйләнечтән юл тизрәк тә, сыйфатлырак та булачак дип ышанам. Ничек кенә булмасын, яңа юл М7 трассасына тоташа бит. Димәк, зур юл да безгә якынаячак.

Алабуга районында М7 трассасыннан борылып, Чулман күпере аша Түбән Кама ягына чыгучы юл Корабельная урманы аша да уза. Биредә агачларны кисеп, булачак юлны күтәрткәннәр инде. Хәтерләсәгез, былтыр тарихи имәннәрне юкка чыгаруга ризасызлык белдерүчеләр дә булды. Юл салып кына эш бетмәвен төзүчеләр дә аңлый. Татарстанда федераль юллар төзелеше барышында киселгән урманнарны яңарта башлаганнар инде. Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы төзелеше кысасында май аенда гына да 150 меңнән артык төп нарат утыртканнар. Рәсми мәгълүматларга караганда, әйләнеч юлны салу өчен урман фондына керүче 260 гектарга якын мәйдандагы җир кишәрлеген төзүчеләргә тапшыру күздә тотыла. Россия Урман Кодексы нигезендә, әлеге җирләрдән файдаланган өчен, компенсация рәвешендә 650 мең төп агач утыртырга туры киләчәк. Әнә шул юнәлештәге эш башланган да инде. Агач утыртуны киләсе елда төгәлләмәкчеләр. Шуннан соң да өч ел дәвамында үсентеләрнең тернәкләнеп китүен күзәтеп торырга ниятлиләр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЧАКЫРСАМ, КАЙТЫРСЫҢМЫ?

Авылда эшләргә барыннан да бигрәк механизатор, сыер савучы, агроном, зоотехник һәм мал табиблары җитми. Сәбәп нидә? Хикмәт хезмәт хакларының аз булуындамы, әллә башкадамы? Әлеге язмада авылда эш, көчле хуҗалыклар юк, дигән фикерне читкә куеп, булган эшкә кеше таба алмау проблемасын күтәрдек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Эше бар – кешесе юк

Хуҗалык җитәкчеләре, фермерлар белән сөйләшкәндә еш кына сыер савучылар һәм механизаторларга кытлык булуын ишетергә туры килә. Әйтик, Актаныш районындагы «Таң» хуҗалыгында 4500 гектар сөрүлек җире, 2500 баш терлек бар. Хуҗалык җитәкчесе Рафис Миңнеханов сүзләренчә, аларда сыер савучылар җитми.

– Безнең колхозда сыер савучыларның хезмәт хаклары уртача алганда – 45–50 мең сум, 60 мең сум алган чаклары да бар. Тик шул акчага да эшләргә кеше табып булмый. Әйе, килешәм, ферма – хуш исле, чиста җир түгел. Миңа калса, хатын-кызларны беренче чиратта шул куркыта торгандыр. Ферма исен берничек тә бетереп булмый, өйгә дә ияреп кайта ул. 50 мең сумга фермага барганчы, мәктәптә 12 мең сумга идән юып кайта да өендә тынычлап тора ул. Югыйсә авылда эшләрдәй кеше юк, дип әйтеп булмый бит, – диде Рафис Миңнеханов.

Авылларда механизаторларга да кытлык бар. Күпчелек хуҗалыкларда аларның хезмәт хаклары уртача 35–40 мең сум, эшне «батырып» эшләгәннәре, уңган-булганнары сезон вакытында 100 мең сумга кадәр акча ала. Димәк, хикмәт хезмәт хакының аз булуында гына да түгел. Шушы ук фикерне Чүпрәле районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Тәлгать Халитовтан да ишеттек.

– Бүген безнең районда барлык хуҗалыкларда да белгечләргә вакансияләр бар, – ди ул. – Бухгалтерлар, агрономнар, инженерлар кирәк. Сыер савучылар, комбайнчылар турында әйтеп тә тормыйм. Агрохолдинглар бухгалтерларга 100 мең сумга кадәр акча вәгъдә итә. Шул хакка да кеше таба алмыйлар. Шуңа күрә авылда эш юк, дигән сүз дөрес түгел. Авылда калганнарга һәм эшләргә теләгәннәргә – эш бар. Тик калучы бармы? Төп сәбәп менә шушы.

Белгечләр

Авылларда, эре хуҗалыкларда эшләр өчен мал табиблары да җитми. Республикада алар белән тәэмин ителеш 83 процентны тәшкил итә. Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Алмаз Хисаметдинов әйтүенчә, ветеринария берләшмәләре карамагындагы ветеринарлар белән тәэмин ителеш 100 процентны тәшкил итә. Ә менә халык белән көн саен элемтәдә була торган белгечләргә кытлык зур. Вазгыять аеруча Чистай (тәэмин ителеш 65 процент), Алабуга (64 процент), Лаеш (56 процент), Югары Ослан (50 процент) һәм Балык Бистәсе (50 процент) районнарында катлаулы.

Балык Бистәсе районының ветеринария берләшмәсе җитәкчесе Динар Сөләйманов фикеренчә, районга кайткан яшь белгечләрнең бик азлары гына төпләнеп кала.

– Иң зур авырлык – көндәлек эшләрне башкаручы белгечләр җитмәү. Хезмәт хаклары белән кызыксындырырга кирәк аларны. Күпчелеге бер ел да эшләмичә китә. Йортлар да салырга кирәк, тик моның өчен алар бераз эшләргә тиеш, дип саныйм. Элек мал табиблары укуны тәмамлагач, авылларга кайтып, кимендә өч ел эшли иде. Шуны кабаттан кайтарырга кирәк. Хәзерге вакытта бездә эшләүчеләрнең күпчелеге – урта буын. Алар барысы да диярлек кайчандыр укуны тәмамлап, безгә эшкә кайтучылар, – диде ул.

Казан дәүләт ветеринария медицина академиясе ректоры Рөстәм Равилов фикеренчә, гадәти белем бирү белән бергә кабаттан практик тәҗрибәгә күчәргә кирәк.

– Чыгарылыш студентлары авылга эшкә барсын өчен мәктәп укучылары белән эшләүне иртәрәк – 7–8 нче сыйныфлардан ук башларга кирәк. Абитуриентларны максатчан укуга да җәлеп итәргә, кызыксындырырга кирәк. Чөнки вузны тәмамлагач, максатчан укыган студентларның 99,5 проценты эшкә урнаша. Тик, кызганыч, районнарда кызыксыну юк. Узган ел ахырында районнарга максатчан килешү нигезендә укырга теләге булган мәктәп укучыларын безгә җибәрүне сорап, хатлар юллаган идек. Алай гына да түгел, бу мәсьәләдә без һәрдаим районнарның авыл хуҗалыгы идарәләре белән элемтәдә торабыз. Ел башында 43 районның бары тик 3есе генә кандидатлар җибәрде. 9 район, кирәкми, диде, 31е хатта җавап та бирмәде, – диде Рөстәм Равилов.

Эшкәртүдә

Авыл хуҗалыгы тармагы ферма, терлек янында эшләү белән генә чикләнми. Алган продукцияне эшкәртергә дә кирәк бит әле. Саба районының данлыклы фермеры Зөфәр Мөхәммәтшин белән сөйләшкәндә: «Үз чималыңны үзең эшкәртү отышлы, әлбәттә, ләкин кем белән эшлисең? Авылда аны башкарып чыгардай кешеләр юк бит», – дигән иде. Шушы ук фикерне республиканың төрле районнарындагы башка фермерлардан да ишетергә туры килгәне бар.

Кайбыч районының Чүти авылындагы «Йолдыз» кооперативы белгече Гөлназ Щукинага үз вакытында технолог һөнәренең үзенчәлекләренә төшенергә туры килгән.

– Эшкәртүдә технологлар гына түгел, ярымфабрикат ясаучыларны да, пилмән бөгүчеләрне дә табып булмый. Хәзерге вакытта миндә пенсия яшендәге хезмәттәшләр сыер савучылар һәм бер яшь кыз эшли. Икенче сменада эшләр өчен биш пилмән бөгүче кирәк. Машина йөртүче, көтүче дә юк. Каз көтәр өчен бер кешене чакырган идек. Аена ике көн ял һәм 15–16 мең сум хезмәт хакы белән. Җаваплылык зур түгел, документ тутырасы юк. Ләкин аңа да риза булмады. Әнисенең пенсиясенә яшәүне кулайрак күрде. Эшлим дигән кешегә авылда эш бар. Кыр эшләрендә дә, фермада да хезмәт хакы начар түгел. Ярымфабрикатлар ясаучылар да аена 20–23 мең сумнан ким акча алмый. Әзер продукцияне төргәкләргә куючыларның гына хезмәт хакы азрак. Алар 16 мең сум акча ала. Ләкин аларның да хезмәт хаклары өстәмә эшләр эшләп тигезләнә.

Авылда эшләр өчен кеше таба алмауның сәбәбе нидә соң? Бу сорауны Гөлназ Щукинага да бирдек. Әлеге дә баягы җавап шул: авыл җирендә эшлим һәм яшим дип торучы яшьләр юк.

– Алар шартлар булмауны сәбәп итә инде, – ди Гөлназ. – Тик кайберләре шәһәрдә фатир арендалап, муеннан бурычка батып, кредит түләп яшәүне яхшырак дип уйлый. Андыйлар ит һәм бәрәңгене авылдан бушлай алып китү ягын карый. Авылда да муеннан сазга батып эшли торган эшләр юк хәзер. Хезмәт хаклары шәһәрнекеннән калышса да, ипотека түлисе, тырышканда, ит һәм сөт алырга кибеткә йөгерәсе юк.

Бишнең берсе генә кайта

Авыл хуҗалыгы белгечләрен Казан дәүләт аграр университеты, Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе һәм 23 колледж белән техникумда әзерлиләр. Югары уку йортларын ел саен – 1300дән артык кеше, урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен 1500дән артык кеше тәмамлый.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Марсель Мәхмүтов сүзләренчә, әлеге уку йортлары республиканың аграр тармагын тулысынча тәэмин итәрлек белгечләр әзерләп чыгара. Тик укуны тәмамлау гына түгел бит әле. Кулга диплом алган егет һәм кызларның авылга эшкә кайтулары да кирәк. Монысы – иң четереклесе. Статистика мәгълүматлары әнә шуны күрсәтә. Татарстанда аграр вузны тәмамлаган 5 белгечнең берсе генә авылга кайта. Калганнар шәһәрне сайлый. Нәтиҗәдә аграр тармакка агроном, зоотехник, мал табиблары җитми. Министр Марат Җәббаров еллык коллегия утырышы вакытында кадрлар белән тәэмин ителеш 79–96 процентны тәшкил итә дигән иде. Аның фикеренчә, бу проблеманы кадрларны максатчан әзерләү программасы хәл итә алыр иде.

Югыйсә югары һәм урта һөнәри белем алып, авылда кем дигәндә өч ел эшләгән яшь белгечләргә һәртөрле ярдәм чаралары да бар. Әйтик, югары уку йортын тәмамлаучыларга бер тапкыр 300 мең сум, техникум дипломына ия булучыларга 150 мең сум пособие түләнә. Боларга өстәп, ике төр категориягә дә хезмәт хакларына ел дәвамында 7500 сум өстәмә каралган.

Моннан тыш, Татарстан белем бирү дәүләт мәгариф оешмаларында көндезге уку бүлегендә федераль белем бирү стандартлары нигезендә югары белем алучы студентларга түбәндәге стипендияләр билгеләнә: Казан дәүләт аграр университеты һәм Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенең 50 студентына ел дәвамында ай саен – 2000 сум, аграр профильле профессиональ белем бирү оешмаларының 50 студентына 1000әр сум бирелә. Шушы ук уку йортларының 3–5 курс студентларына республиканың авыл хуҗалыгы оешмаларында практика узган вакытта ике ай дәвамында 1әр мең сум күләмендә стипендия каралган.

Шулай ук фәнни оешмаларның һәм Татарстанның аграр профильле югары белем бирү оешмаларының министрлык тарафыннан расланган тематик планнары нигезендә фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче кече фәнни хезмәткәрләренә ай саен 5әр мең сум күләмендә стипендия түләнә. Болардан тыш, бүген квалификация күтәрүгә, белгечләрне яңадан әзерләүгә һәм фәнни тикшеренүләрне үстерүгә республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы 100 млн сумга якын акча тота. Студентларны укыту һәм практика өчен предприятие чыгымнары да субсидияләнә. Әлеге программада 107 предприятие, 400 студент катнашкан.

ТАТАРСТАНДА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТАРМАГЫНДА БЕЛГЕЧЛӘР ҺӘМ ЭШЧЕЛӘР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШ

Белгечләр буенча

Кеше	Тәэмин ителеш
агрономнар.................483	85%
зоотехниклар...............296	82%
ветеринарлар..............628	83%
инженерлар................645	91%
экономистлар..............377	94%
бухгалтерлар.............1377	96%

Эшчеләр буенча

Кеше	Тәэмин ителеш
механизаторлар..........6765	88%
терлекчеләр................9381	95%
машина йөртүчеләр.....2785	86%
башка төр белгечләр....1725	87%

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары

Газетаның «ВК» сәхифәсендә уздырган сораштыру нәтиҗәләре

НИ ӨЧЕН АВЫЛЛАРДА ЭШЛӘРГӘ КЕШЕ ҖИТМИ?

- Хезмәт хакы аз...**62,34%**
- Торыр урын юк..**1,95%**
- Авылда эшләрдәй кеше бетте.................................**17,53%**
- Халык ялкауланды, җиңел юл эзли........................**18,18%**

«АК ЧӘЧӘКЛӘР» БӘЙГЕСЕНДӘ МАХСУС БҮЛӘККӘ ИЯ БУЛГАН ЕЛЕНА РОДИОНОВА:

«БАЛА ТАБУ – БИК ЗУР ХЕЗМӘТ УЛ»

Быелгы «Ак чәчәкләр» бәйгесендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның махсус бүләгенә акушер Елена Родионова лаек булды. Бәйрәмнән «Лада Гранта» машинасында кайтып киткән ханым Яшел Үзән район үзәк хастаханәсендә эшли. Тәҗрибәле белгеч белән әниләр һәм бәбиләр, аларның сәламәтлеге, һөнәр үзенчәлеге турында сөйләштек.

:: Елена ханым, Рәис кулыннан мондый зур бүләк алырга өметләнгән идегезме?

– Мондый бәйгедә беренче тапкыр гына катнаштым. Сәхнәдән минем исемем яңгырагач, бер мәлгә өнсез калдым. Каушаудан аякларым тотмаска әйләнде. Кулга машина ачкычын алгач, ничек кире үз урыныма төшеп утырганны да хәтерләмим. Татарстан Рәисенең махсус бүләгенә лаек булу – минем кырык елга якын яратып башкарган хезмәтемә зур бәя ул. Минем хезмәтемне болай югары бәяләүләре өчен зур рәхмәт!

:: Беренче тапкыр бала таптырган көнегезне хәтерлисезме?

– Хәтерлим, әлбәттә. Кулларымның ничек дерелдәве бүгенгедәй хәтердә. Баланың кендеген кисүемдә, кайчыны көчкә тоттым, үлеп терелгәндәй булдым. 37 елдан бирле бала тудыру йортында эшлим. Башта өч ел санитар хезмәткәр булып эшләдем, аннары акушерлык эшенә керештем. Күпьеллык тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: бу дөньяда бала туудан да могҗизалырак күренеш юк. Яңа туган сабыйның беренче тапкыр тавыш биреп, елап җибәрүе нинди хисләр уятканын сүз белән генә аңлатырлык түгел. Һөнәрем барыннан да бигрәк әнә шул ягы белән күңелемә якын. Әнием дә гомер буе безнең бала тудыру йортының яңа туган балалар палатасында эшләде. Шуңа бу эш миңа кечкенәдән якын.

:: Тормыш коточкыч тизлек белән үзгәрә. Кем әйтмешли, хәзер балалар да башкача туадыр?

– Безнең эшнең беркайчан да җиңел чагы булганы юк. Соңгы елларда кәгазь эшенә компьютер да өстәлде. Мәгълүматларны шунда да кертеп барабыз. Бер яктан, бу бик уңайлы, икенче яктан, эшебез тагын да артты. Соңгы елларда яңадан-яңа заманча технологияләр кулланыла, бар нәрсә камилләшә бара. Эш шартлары да бөтенләй башка.

:: Ә яшьләр киләме? Тәҗрибәле табибләр арасында аларны тәнкыйтьләүчеләр дә аз түгел.

– Каршылыклы фикерләрне медицинада гына түгел, теләсә кайсы тармакта ишетергә мөмкин. Хәзер медицина юнәлешендә укып чыккан күп кенә яшь белгечләр озак еллар эшләүчеләргә караганда да белемлерәк. Аларның күбесенең киләчәге өметле. Медицина тармагында эшләргә теләүчеләр шактый булса да, кызганыч, араларында акушер һөнәрен сайлаучылар күп дип әйтеп булмый. Әмма безгә лаеклы алмаш булачагына ышанасы килә.

:: Бәбиләрнең әниләре ни хәлдә?

– Кызганыч, хатын-кызларның сәламәтлеге елдан-ел начарлана бара. Моңа экология дә, компьютер, телефон ише заманча уенчыкларга бәйле булуыбыз да сәбәпче. Әни кешенең сәламәтлеге турыдан-туры карындагы балага да йогынты ясый. Шуңа күрә соңгы арада умыртка баганасы кәкрәю, күзе начар күрүдән азапланган балалар саны артуга да аптырарлык түгел. Соңгы арада адым саен вейп тарткан хатын-кызлар да күбәйде. Зарарсыз дип уйлап, организмына ни дәрәҗәдә зур зыян салганын күз алдына да китерми алар. Хәтта йөкле хатын-кызлар да шул көтешүгә көйрәтә. Кан аша ул бит карындагы бала организмын, бигрәк тә аның баш миен агулый. Шуңа күрә хәзерге ата-аналар буыны да, балалар да күпкә зәгыйфьрәк. Гүзәл затлар елына бер тапкыр булса да хатын-кыз табибына күренергә тиеш. Хәтта бернәрсә борчымаса да барырга кирәк. Кайбер авырулар алдан үзен сиздерми, ә ачыклангнда инде соң булырга мөмкин.

:: Кайсы чирләр аеруча еш очрый?

– Соңгы арада хатын-кызлар арасында җенси юл белән күчкән авырулардан интегүчеләр шактый. Алар, нигездә, тәртипсез тормыш алып баручыларда очрый. Ялкынсыну, күрем циклы бозылу очраклары да еш күзәтелә. Хатын-кыз, бигрәк тә кыз бала даими рәвештә салкын тиеп авырса, аның кече оча сөяге өлешендә ялкынсыну башланырга мөмкин. Бу исә – киләчәктә ул йөккә уза алмыйча тилмерергә мөмкин дигән сүз. Хәзер кызларны балалар бакчасыннан ук хатын-кыз табибына йөртәләр. Дөрес эшлиләр. Авыру никадәр иртәрәк ачыкланса, дәвалауга да шулкадәр җиңелрәк бирешә алар.

:: Сорамый булдыра алмыйбыз: коронавирус хатын-кыз организмына нинди йогынты ясады?

– Коронавирус хатын-кыз, бигрәк тә йөкле хатын-кыз организмы өчен зур сынау булды. Пандемия чорында ковид йоктырган хатын-кыздан бала таптырырга туры килде. Андый чакта организм, иң беренче чиратта, кислородка кытлык кичерә. Бала тапканнан соң кан тuktамый тилмертә. Бу ана өчен дә, карындагы бала өчен дә куркыныч. Йөклелек чорында коронавирус кичергән хатын-кызның баласы да еш кына ялкынсыну белән туа. Тәнендә тимгелләр була. Теләсә кайсы инфекция кебек үк ковид та хатын-кыз организмын зәгыйфьләндерә, аның репродуктив системасына тискәре йогынты ясый.

Гомумән, хатын-кызның сәламәтлеге генә түгел, психологиясе дә шактый үзгәрде.

> Элек хатын-кызлар рухи яктан да, физик яктан да көчлерәк иде. Алар үзеннән бигрәк, иң беренче чиратта, туачак баласы турында уйлый иде. Хәзер исә хатын-кызлар күпкә йомшаграк, иркәрәк.

Үзләрен бәллүр ваза итеп күз алдына китерә алар. Күпләр бала таптырган мизгелдә дә көйсезләнеп, баласы турында уйлыйсы урынга, үзен көйләтергә маташа. Андыйларга карата катырак торырга туры килә. Ник дигәндә, бала таптырган мәлдә һәр секунд исәптә. Монда соңгы арада популярлашып киткән психологларның да өлеше зурдыр. Алар, тырыша-тырмаша, үз-үзеңне яратырга өйрәтә бит хәзер. Бала табу – бик зур хезмәт. Әни булырга җыенган кеше рухи яктан да, физик яктан да шуңа әзер булырга тиеш.

Соңгы арада беренче баласын 30–35 яшьтән соң гына табучылар күбәйде. Элегрәк бу хатын-кыз өчен соң дип санала иде. Әмма хәзер медицина бик нык алга китте. Шуңа күрә бу яшьтә дә хатын-кыз йөклелек чорын җиңел уздырып, сау-сәламәт бала таба ала. Хәтта кырыктан соң да хатын-кыз курыкмыйча бала таба ала хәзер. Шулай да шәхсән үзем беренче баланы 25 яшьтән дә соңга калмыйча алып кайтырга кирәк дип саныйм. Бу ана өчен дә, бала өчен дә яхшырак.

:: Әтиләрдә үзгәреш сизеләме?

– Хәзер әтиләр сабырсызрак. Аларга бар нәрсә тиз генә кирәк. «Таптымы инде? Ник һаман хәбәр юк?» – дип әллә ничә тапкыр шалтырата, сорашалар. Бала табу йортының тәрәзә төбендә тыныч кына көтеп утырган әтиләр үткәндә калды. Күп булмаса да, хатыны бала тапканда янында басып торган ир-атлар да бар.

:: Яшерен-батырын түгел, районда бала табарга куркып, зуррак шәһәргә баручылар да шактый. Бу хакта сезнең фикер ничек?

– Бала тапканда ни буласын алдан фаразлап булмый. Әгәр хатын-кыз сау-сәламәт икән, ул теләсә кайда уңышлы гына бала таба алачак. Райондамы ул, шәһәрдәме – мөһим түгел. Организмында хилафлык булган очракта хатын-кыз тулгагы башланганчы ук шәһәр бала табу йортына озатыла.

:: Хатын-кызлар күбрәк бала таба башласын өчен, эшне нидән башларга дип саныйсыз? Бала төшертүне тыюны итәргә кирәк, диючеләр дә бар.

– Моңа җаным-тәнем белән каршы мин. Бу законсыз рәвештә – качырып-яшереп бала төшертү очраклары артуга китерәчәк. 1980 нче елларда, мин әле акушер булып эшли генә башлаган елларда да андый аянычлы очраклар бик күп күзәтелде. Ул чорда законсыз юл белән баласын төшертү хатын-кызларны бик күп китерделәр. Аларның күбесенең каны агуланырга, организмында җитди өзелгүләр башланырга өлгергән иде. Ул хәлләр әле дә куркыныч төш кебек күз алдымда тора.

Әйе, хәзер хатын-кыз бала алып кайтырга атлыгып тормый.

> Кеше рәхәттән-рәхәткә генә яшәргә тели. Яшьләр авызыннан: «Үзем өчен яшисем килә», – дигән сүзләрне дә торган саен ешрак ишетергә туры килә. Аларның күбесе бала табуны да өстәмә мәшәкать итеп кабул итә.

Күбрәк бала тууын теләсәк, сәламәт яшәү рәвешен яхшырак пропагандаларга, балаларга кечкенәдән гаилә кыйммәтләрен сеңдерергә кирәк. Хатын-кыз үзеннән соң эз калдырырга, бер тапкыр булса да әни булырга тиеш. Бала табу өчен матди яктан кызыксындыру чаралары да күбрәк булсын иде.

Әңгәмәдәш – Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«ЕЛ ТАБИБЫ – АК ЧӘЧӘКЛӘР – 2023» БӘЙГЕСЕНДӘ ҖИҢҮЧЕЛӘР

«Ел табибы» – Айнагөл Баялиева.
Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының анестезиология һәм реаниматология буенча штаттан тыш баш белгече, Казан дәүләт медицина университетының анестезиология һәм реаниматология, һәлакәтләр медицинасы кафедрасы мөдире. Йөрәк күчереп утырту буенча беренче операцияләрдә катнаша. Республиканың әйдәп баручы клиникаларында берничә инновацияле методика кертә.

«Сәламәтлек саклау легендасы» – Дмитрий Красильников.
Ул – Татарстанда беренче булып, бавырны күчереп утырткан һәм башка катлаулы операцияләр ясаган кеше. Медицина фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт медицина университетының 1 нче хирургия авырулары кафедрасы мөдире.

«Уникаль очрак» – Чаллы шәһәренең Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе табиблары.
Алар, Россиядә беренчеләрдән булып, кеше организмындагы иң зур кан тамырларын алыштырган.

«Беренчел звеноның иң яхшы табибы» – Николай Романов.
Яшел Үзән үзәк район хастаханәсенең участок педиатры. Ул эшләгән өч ел вакыт эчендә район үзәк хастаханәсенең педиатрия бүлегендә балаларны диспансерлаштыру, вакцинацияләү күрсәткечләре яхшырган.

«Елның медицина хезмәткәре» – Миләүшә Шәрәфетдинова.
Республика клиник онкология диспансеры шәфкать туташы. 33 ел дәвамында катлаулы операция кичергән авыруларга ярдәм итә.

«Сәламәтлек саклауның мактаулы остазы» – Марс Михайлов.
Медицина фәннәре докторы, академик, профессор, Россия һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясенең биология һәм медицина фәннәре бүлеге академик-сәркатибе. 60 елдан артык гомерен сәламәтлек саклауга багышлаган шәхес.

26 июнь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Ком сәгате» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Гаилә учагы» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Николай Морозов. Объять необъятное 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Атылган йолдыз эзләреннән. Ф. Яруллин» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Фәннур Сафин турында телеочерк 16+
15.30, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Адымнар» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Сәләт» 6+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Калеб» 6+
02.45 «Караоке татарча» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Юлия Снигирь в исторической драме «ВЕЛИКАЯ» (S) 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
23.25 «Вечер» 12+
02.05 «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.55 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 23.30 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
07.00, 10.00, 12.30, 16.55, 19.05, 22.30 Новости
07.05, 20.35, 22.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 20.15 Специальный репортаж 12+
10.25 Дзюдо. Fonbet Российский профессиональный тур. Трансляция из Челябинска 0+
11.25 Смешанные единоборства. One FC. Супербон Сингха Мавинн против Чингиза Аллазова. Трансляция из Таиланда 16+
12.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Прямая трансляция из Екатеринбурга
15.10 «Кулачные бои». Документальный фильм 16+
17.00 «Громко». Прямой эфир
18.00, 19.10 «Эра медведей». Телевизионный сериал 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.30 Автоспорт. G-Drive Российская серия кольцевых гонок. Трансляция из Казани 0+
01.00 Прыжки в воду. Чемпионат России. Трансляция из Екатеринбурга 0+
02.00 Новости 0+
02.05 «Вы это видели» 12+
02.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Васко да Гама» – «Куяба». Прямая трансляция

НТВ

04.55 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее»
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.40 «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00 «ФЕНИКС» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Андрей Бурковский, Юлия Пересильд, Дарья Мороз в детективном сериале «МЕДИАТОР» (S) 16+
00.45 «ТЕРМИНАЛ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Наказать обидчика» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ» 16+
19.00 «ПРИСЯЖНАЯ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.35 «Порча» 16+
01.05 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
02.30 «Тест на отцовство» 16+
04.10 «Давай разведёмся!» 16+
05.00 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.50 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «РЫСЬ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00 «ЕСЛИ ВРАГ НЕ СДАЕТСЯ...» 12+
12.50, 13.25, 15.05 «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.25, 17.15 «БУДУ ПОМНИТЬ» 16+
18.00 «На пороге войны». Документальный сериал. «Битва за Поднебесную» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Загадки века». Документальный сериал. «Афёра тысячелетия. Как американцы хранят чужое золото» 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «НЕНАВИСТЬ». Телесериал. 1-я – 3-я серии 16+
02.10 «ПРИКАЗ: ОГОНЬ НЕ ОТКРЫВАТЬ» 12+
03.40 «ПРИКАЗ: ПЕРЕЙТИ ГРАНИЦУ» 12+
05.05 «Оружие Победы». Документальный сериал 12+

27 июнь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Певец Владимир Васильев 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.5 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.20, 03.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Корбан гаете мөбарәк булсын!» Турыдан-туры трансляция 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ». Многосерийный фильм (S) 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ольга Ломоносова, Дмитрий Ульянов, Михаил Евланов, Дмитрий Орлов, Анатолий Горячев, Анатолий Котенёв, Кирилл Гребенщиков, Инга Оболдина, Илья Любимов, Александр Яцко, Эдуард Радзюкевич. «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анастасия Веденская, Сергей Губанов, Сергей Рудзевич, Виолетта Давыдовская, Любовь Германова. «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.55 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 23.30 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «Андрей Аршавин меняет профессию» 12+
07.00, 10.00, 12.30, 16.55, 19.05, 22.30 Новости
07.05, 17.00, 20.35, 22.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 20.15 Специальный репортаж 12+
10.25 «Футбол на все времена» 12+
11.25, 18.00, 19.10 «Эра медведей». Телевизионный сериал 16+
12.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Прямая трансляция из Екатеринбурга
16.25 «География спорта. Казань» 12+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.30 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+
01.00 Прыжки в воду. Чемпионат России. Трансляция из Екатеринбурга 0+
02.00 Новости 0+
02.05 «ФК «Барселона». Взгляд изнутри». Документальный фильм 12+
04.00 Дзюдо. Fonbet Российский профессиональный тур. Трансляция из Челябинска 0+
05.05 Триатлон. Мировая серия. Мужчины. Трансляция из Канады 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее»
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.40 Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ФЕНИКС» (S) 16+
22.15, 00.00 Премьера. Детективный сериал «МЕДИАТОР» (S) 16+
00.45 Детективный сериал «ТЕРМИНАЛ» (S) 16+
04.45 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Ведьма» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ЛЮБОВЬ ЛЕЧИТ» 16+
19.00 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА САНТЕХНИКА» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.35 «Порча» 16+
01.05 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
02.30 «Тест на отцовство» 16+
04.10 «Давай разведёмся!» 16+
05.00 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.50 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00 «ДОБРОВОЛЬЦЫ» 12+
13.35, 15.05, 17.15 «НЕМЕЦ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «На пороге войны». Документальный сериал. «Польша. Между Гитлером и Черчиллем» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Дело о тепловизорах. От Сталинграда до Соледара. Тайна двух окружений» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «НЕНАВИСТЬ». Телесериал. 4-я – 6-я серии 16+
02.10 «БУДУ ПОМНИТЬ» 16+
03.45 «Сделано в СССР». Документальный сериал 12+
04.00 «НЕМЕЦ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык намуслы хезмәте, нәтиҗәле иҗади һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Айзетуллова** Гөлнур Хәлил кызы; республикада медицина-социаль экспертизасы системасын камилләштерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесенең учреждение эшчәнлегенең гомуми мәсьәләләре буенча урынбасары **Алишева** Светлана Нурислам кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең икътисадый үсеш комитеты фаразлау һәм индикатив идарә бүлеге башлыгы **Брыкалина** Лариса Васильевна; торак-коммуналь хуҗалык тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Минзәлә районының коммуналь челтәрләре» акционер җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм фаразлау буенча урынбасары **Габдрахманова** Сәлимә Миргалләм кызы; халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Казан шәһәре «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесенең 2 номерлы троллейбус депосы техник хезмәт күрсәтү участогының майлаучысы **Ларюхин** Юрий Павлович; законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды суд составы рәисе **Нәфиков** Рәсим Миннәхмәт улы; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм республиканың төзелеш тармагын үстерүгә өлеш кертүе өчен «Кама Тамагы гипс руднигы» акционер җәмгыяте баш бухгалтеры урынбасары **Пархутина** Наталья Николаевна; эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының тыл башлыгы урынбасары, эчке хезмәт полковнигы **Фәизов** Фәрид Наил улы; халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Казан шәһәренең «12 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Һадиева** Вәсилә Зөфәр кызы; мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Техника йорты» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе директоры (Бөгелмә шәһәре) **Хөсәенова** Любовь Ильинична; халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүдәге казанышлары һәм намуслы хезмәте өчен «Ошель» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шәйхетдинов** Марат Наил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Казан хореография училищесы» (техникум) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе концертмейстеры **Бажин** Илья Сергеевичка, Казан шәһәренең «А.С. Ключарев исемендәге 7 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Гарәпшина** Эльмира Фавис кызына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының проектларга идарә бүлеге башлыгы **Мусин** Нияз Илдус улына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең телевидение музыкаль һәм әдәби программалар баш редакциясе режиссеры **Мөхәммәдиева** Зөлфирә Рамазан кызына, Казан шәһәренең «Х.Г. Якупов исемендәге 1 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең рәсем, сынлы сәнгать һәм композиция укытучысы **Орлова** Галина Михайловнага, «Казан хореография училищесы» (техникум) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының оештыру эшчәнлеге буенча урынбасары **Попова** Татьяна Александровнага, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының стратегик планлаштыру һәм фаразлау бүлеге башлыгы **Хәсәнова** Диана Рөстәм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең хезмәткә өйрәтү һәм рәсем укытучысы **Бартязова** Светлана Альбертовнага, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Шәпше урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Вәлиуллина** Сөмбел Мөхәммәт кызына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Габдрахманов** Илдус Нурислам улына, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының аерым фәннәр тирәнтен өйрәтелә торган 16 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Гайсина** Суфия Искәндәр кызына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең «Елмаю» 18 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Гембель** Татьяна Владимировнага, «Батырлык ордены кавалеры Дмитрий Бәдретдинов исемендәге 46 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы (Чаллы шәһәре) **Гыймадиева** Фәридә Галимҗан кызына, «Е.Н. Королёв исемендәге Түбән Кама политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Куприянова** Татьяна Адиславовнага, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 3 номерлы гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы **Маликов** Владимир Евгеньевичка, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәренең «Кояшкай» катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе укытучысы-логопеды **Сабирҗанова** Илһамия Рифкать кызына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Киндер Күл авылы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире **Сабирова** Гөлнара Каюм кызына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең технология укытучысы **Тимерханов** Камил Габделхай улына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Осиново авылының «Аленушка» 25 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе өлкән тәрбиячесе **Шулаева** Лидия Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЮЫП КАП

Көтеп алган җәй еш кына төрле чирләр белән дә истә кала. Бигрәк тә пычрак куллар аша эләккән йогышлы авырулар, агулану очраклары еш очрый. Андый чакта ни эшләргә? Җәйге чорда ризык белән агуланган кешегә ничек ярдәм итәргә?

Табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНАның бу уңайдан киңәшләрен тәкъдим итәбез.

☑ Ризык белән елның теләсә кайсы вакытында агуланырга мөмкин. Әмма җәйге чорда андый аянычлы очраклар ешрак күзәтелә. Бу аңлашыла да. Җәй көне ризыклар бик тиз бозыла. Хәтта суыткычта саклананнары да вакытыннан алда ашарга яраксызга әйләнергә мөмкин. Шуңа күрә җәй көне ризык сатып алганда, бигрәк тә яшелчә, җиләк-җимеш сайлаганда аеруча игътибарлы булырга кирәк. Аларның тышкы кыяфәтенә, исенә, төсенә аеруча игътибар итәргә кирәк. Анда кителгән, бозылган, черегән урыннар булмаска тиеш. Кайткач, сатып алган яшелчә, җиләк-җимешләрне агып торган суда яхшылап юарга кирәк. Кисеп, яртылаш сатылган җиләк-җимешләрне бөтенләй читләтеп үтү хәерле.

☑ Ризык белән агуланган кешенең, иң беренче чиратта, күңеле болгана башлый. Ул коса, эче китә, башы авырта, температурасы күтәрелә. Дөрес, бу билгеләр күп кенә башка чирләр вакытында да күзәтелергә мөмкин. Шуңа күрә алда телгә алган үзгәрешләрнең берсе генә булса күзәтелсә дә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итегез.

☑ Ризык ашап агуланган кешегә ничек ярдәм итәргә? Иң беренче аның ашказанын юдырырга кирәк. Моның өчен аңа рәттән ике стакан су эчертеп костыралар. Аннары аңа 10 килограмм гәүдә авырлыгына бер төймә исәбеннән активлаштырылган күмер эчертәләр. Эч йомшарта торган дару, клизма ясау да ярдәм итәчәк.

☑ Агуланганда организм бик күп су югалта. Шуңа күрә кешенең хәле бераз уңайлангач, аңа мөмкин кадәр күп итеп чиста су эчертергә кирәк. Газы чыгарылган минераль су да эчәргә мөмкин. Полисорб кебек сорбентлар да ярдәм итәчәк. Берничә көн дәвамында диета саклап, җиңелчә тукланырга да туры киләчәк. Ризык белән агуланган кешегә ашказанын, эчәкләрне ярсыта тора ризыклар ашаудан тыелып торырга кирәк. Бу чорда боткалар, майлы булмаган шулпа, куе чәй эчү, сохари ашап тору хәерле.

☑ Җәйге чорда агулану, төрле инфекцияләр йоктырудан саклану өчен, кулларны да даими рәвештә юарга кирәк. Шунысын да онытмагыз: җәй көне кайнатылган су яки шешәдәге суны гына эчү яхшырак. Билгесез чыганаклардан су эчүдән сакланыгыз.

vk.com

АГУЛАНУ КУРКЫНЫЧЫН АРТТЫРА

Җебегән туңдырма – алтынсу стафилококк бактерияләре үрчү өчен менә дигән җирлек.

Суши, ролларны ясаганда кулланылган балык эсседә бик тиз бозыла. Суши, роллны өйгә китерткәндә бу куркыныч тагын да арта. Аны тиешле температура режимы саклаган махсус букчада алып килмәгән булулары да бар.

Карбыз. Дымлы урында сакланган яки өлгермәгән килеш вакытыннан алда өзеп алынган карбыз белән дә агуланырга мөмкин.

Яшел тәмләткечләр – паразит суалчаннар белән эчәк таякчыгы бактериясенең иң яраткан урыны. Шуңа күрә яхшылап юмаган очракта файдалы дип саналган яшел тәмләткеч ашап та агуланырга була.

Бакча җиләге авыз суларын китереп, әллә кайдан үзенә җәлеп итеп торган иң пычрак җиләк санала. Ник дигәндә, агулы пестицид һәм нитритларны бик яхшы сеңдерә ул. Моннан тыш аңа шул ук паразит суалчаннар, бактерияләр иләшкән булуы да бар. Бакча җиләге читтән кайтарылган очракта аны, алда әйтелгәннәргә өстәп, химикатлар белән дә эшкәртәләр.

Баллы ризыкларның эчлегендә кулланылган май эсседә бик тиз бозыла. Ачылган торт, пирожныйны хәтта суыткычта да 36 сәгатьтән артык сакларга ярамый.

Сатып алынган шашлык. Җәй көне үзең сатып алган иттән үзең маринадлап ясаган шашлык кына куркыныч тудырмый. Сатып алынганы бик куркыныч. Төрле тәмләткечләр ярдәмендә иске, хәтта бозылган иткә дә яңа сулыш өрергә мөмкин.

Табигать дарунанәсе

Кишер – йөрәккә дәва

Бакчада үскән кишернең яфрагы да файдалы. Кишер яфрагында файдалы матдәләр кишернең үзе белән чагыштырганда 500 мәртәбә күбрәк, ди галимнәр. Бу яшелчә матурлык чыганагы булган А, иммунитетны ныгытучы С, нерв системасына, бавыр эшчәнлегенә уңай йогынты ясаучы В витаминнарына, сөякләрне, тешләрне ныгытучы калий һәм К витаминына бай.

• Кишер яфрагын кичтән чәй кебек пешереп куеп, икенче көнне эчәргә мөмкин. Бер айлап эчсәң, бавыр чирләреннән, йөрәккә, күзгә шифасы зур була. Аны кышкылыкка киптереп кую да яхшы.

• A, D, B витаминнарына бай кишердә кальций, селен, цинк, магний, фосфор да бар. Организмга кирәкле каротин дигән матдә пешергәндә дә файдалы үзлекләрен югалтмый. Кишер эчәкләрнең дөрес эшләвен тәэмин итә, күз күрүен яхшырта, иммунитетны ныгыта, аппетитны ача, бит тиресенең төсен матурлата.

• Яңа кишерне кабыгын әрчемичә ашау файдалы, чөнки аның тышында иң күп санда фитонцид матдәләр бар. Кишернең кабыгы, үзәк өлешенә караганда, шикәр һәм башка туклыклы матдәләргә күпкә баерак.

• Никадәр генә файдалы булса да, кишерне чамасын белеп кенә ашарга кирәк. Бигрәк тә йөкле хатын-кызларга, гастрит кебек ашказаны авыруларыннан, аллергиядән интеккән кешеләргә кишер белән артык «дуслашмаска» киңәш ителә.

• Кишер кушылган яки кишер суыннан ясалган битлекләр бит тиресенә бик яхшы тәэсир итә икән. Чәчләре коелган һәм тырнаклары зәгыйфь булган кешеләргә дә әлеге яшелчәне кулланырга киңәш итәләр.

• Кишердән компресс. Кишер тән тиресендәге яраланган, ялкынсынган урыннарны да тиз арада дәвалый. Моның өчен андый урынга ботка рәвешенә килгәнче вакланган кишер куеп торырга кирәк. Өстеннән кәгазь белән каплап, бәйләп куярга онытмагыз. Марля яки мамык кулланырга киңәш ителми. Алар кишернең согын сеңдерәчәк. Кояшта кызынганнан соң янган тән тиресенә дә юка итеп киселгән кишер телеме куеп торырга киңәш ителә.

• Ларингит, ангина вакытында. Ларингит кебек инфекцияле сулыш юллары авыруы вакытында кишер согы ярдәмгә килә. Андый чакта бер стакан кишер согына 1 аш кашыгы бал болгатып эчәргә кирәк. Ангина вакытында 100 грамм кишер согына 100 грамм су, 1 аш кашыгы бал салып, тамакны чайкату да шифалы булачак.

Киңәш-табыш

Керән шифасы

1 Трахеит, бронхит вакытында 1 аш кашыгы уылган керән тамырына 3 аш кашыгы бал кушып төнәтергә, шуны көненә 5 тапкыр 1 чәй кашыгы күләмендә ашарга кирәк. Ул авызда эреп китәргә тиеш.

2 Цистит, уретрит борчыса, 1 аш кашыгы уылган керәнгә 1 стакан кайнар су коеп, 5 минут төнәтегез. Аны көн саен 3–4 чынаяк эчәргә кирәк.

3 200 г уылган керәнгә 3 л кайнап суынган су кушып, 15 минут кайнатыгыз. Шуны иртәнгә кадәр суытыгыз. Иртән исә сөзеп, суыткычка куегыз. Көнгә өч тапкыр, ашар алдыннан 100 г күләмендә эчәргә кирәк. Бер ай тәнәфестән соң дәвалану курсын дәвам иттерергә мөмкин.

Әлеге төнәтмә кан басымын көйли. Шушы ук төнәтмә тагын бик күп чирдән коткара.

Үзем сынадым

Геморройдан котылдым

Озак еллардан бирле геморройдан интегәм. Даруханәдән алган шәмнәр вакытлыча гына ярдәм итә. Күптән түгел түбәндәге рецептны табып, кулланып караган идем, файдасын күрдем. 100 г даруханәдә сатыла торган яшь имән кайрысы, 1 кап лавр яфрагы, 1 уч сары мәтрүшкә, 1 уч бөтнекнең барысын да бергә бутап, 10 л суда кайнатырга, аннары томаларга кирәк. Икенче көнне аны сөзеп, шушы суда утырасы булачак. Суның җылылыгы тән температурасыннан артмаска тиеш. Анда күпме озак утырсаң, шулхәтле әйбәтрәк. Процедураны 10 көн эшләргә кирәк.

Әлфия ИБРАҺИМОВА

САРЫМСАК ТА ИГЪТИБАР СОРЫЙ

«Сарымсак иң мәшәкатьсез яшелчәләрдән санала. Тик аны да башка яшелчәләр кебек үк тукландыру турында онытмаска кирәк», – ди һәвәскәр бакчачы Гөлфия Хәнипова.

vk.com

Тиздән сарымсакны алыр вакыт та җитә. Шуңа ул мул уңыш бирсен өчен, хәзер соңгы тапкыр тукландырып калырга кирәк. Әлеге эшне сарымсак укларын җыеп алганнан соң ике көн үткәч башкару яхшы. Угы кисеп алынган урыны кибеп, ул артык дым югалтмасын өчен шулай эшләнә.

Түбәндәге ысуллар белән тукландырган очракта сарымсак башлары эрерәк һәм кышка да чыдамрак булыр. Тукландыру алдыннан сарымсакка су сибеп чыгарга онытмагыз.

1 ысул. 10 л суга 1 л агач көле салып болгатырга һәм ике сәгатьтән 1 кв. метр мәйданга 5 л исәбеннән сибәргә. Әзер тонәтмәгә су саласы түгел.

2 ысул. 10 л суга 1 аш кашыгы магний сульфаты, 1 аш кашыгы суперфосфат һәм шул ук күләмдә калий сульфаты салып болгатырга һәм сибәргә.

3 ысул. 2 аш кашыгы калий монофосфатын 10 л суга салып болгатырга һәм сибәргә.

Укларын җыйганнан соң сарымсакка су сипмәсәң дә ярый дип уйлыйлар. Яхшы уңыш җыеп алу өчен, аңа да 7–10 көн саен су сибеп торырга кирәк. Әлбәттә, монда чама хисен онытып җибәрмәгез, туфрак кирәгеннән артык юеш түгел, ә дымлы гына булсын. Чөнки күп су сибү тамыр черүгә һәм башка авыруларга сәбәпче булырга мөмкин.

Рецептлар

Блогер Дания Дәүләтҗанова сарымсак укларын ташламаска киңәш итә, аннан бик тәмле май ясап була икән.

✓ **Кирәк:** *сарымсак угы, укроп, рәйхан һәм атланмай (сливочное масло).*

Барысын да чама белән алам. Боларның бөтенесен бергә блендерда вакларга, кирәк дисәгез, бераз тоз өстәргә була. Мондый тәмле май бутербродлар өчен бик яхшы.

✓ **Кирәк:** *сарымсак угы, укроп, рәйхан, әстерхан чикләвеге, зәйтүн мае.*

Барысын да блендерда ваклыйбыз һәм зәйтүн мае салып болгатабыз. Бу хуш исле май белән салатлар һәм шашлык бик тәмле була.

ГОРЧИЦАЛЫ КЫЯР

Юлия ИСӘНБАЕВА рецепты

3 литрлы банкага кирәк: *3 аш кашыгы шикәр комы, 1 аш кашыгын өеп тоз, 3 аш кашыгы 9 процентлы аш серкәсе, 7 тырнак сарымсак, 4–5 укроп кәрзине, 1 чәй кашыгы горчица орлыгы, 7 данә кара борыч. Теләсәгез, карлыган, чия, кура җиләге яфраклары һәм керән тамыры салырга мөмкин.*

Кыярларны стерильләштергән банкаларга тутырабыз. Кайнап торган су салып, 15 минут тотабыз. Аннары кыярга салып торган суны кәстрүлгә салабыз, аңа тоз, шикәр комы, борычны салып, акрын утта 10–15 минут кайнатып, тозлык әзерлибез. Ул кайнаган арада банкаларга укроп, сарымсак һәм горчица орлыгын салып чыгабыз. Аннары банкаларга тозлыкны һәм өстенә серкә салып, калай капкачлар белән ябып, бер тәүлек җылы әйбергә төреп тотабыз.

Исеңдә тот!



Ак кроссовканы чистарту

Бер аш кашыгы ацетонга шул ук күләмдә аш серкәсе салып болгатыгыз. Мамык яки мамык дискка әлеге катнашманы салып, алдан чистартылган кроссовканы ышкып чыгабыз. Ахырдан чиста юеш чүпрәк белән сөртеп алырга онытмагыз.

Бакчачыга

ИЮЛЬДӘ УТЫРТЫРГА МӨМКИН

Җәй уртасында бакчада нәрсәләрне кабат утыртырга була, дисезме? Редис, салат, яшел тәмләткечләр, кара һәм ак торманы июльдә утыртырга мөмкин. Шулай ук бушаган түтәлләргә сидерат буларак горчица, солы һәм вика сибеп куярга да онытмагыз.

Белеп тор!

Төбен кара

Кура җиләгенә даими су сибеп торырга кирәк. Әлбәттә, дымлы җиләк куагы төбен чүп үләннәр дә үз итәр, ә алар исә – корткыч бөҗәкләр яшеренеп яту өчен менә дигән урын. Мәсәлән, гөбләнгенә алайк. Ул кура җиләгенә иялəшсә, нинди генә бөҗәкләр җыелмаячак! Кырмыска, камка иялəшә, яфраклары бөтерелә, килгән зыяннан үсүдән туктарга да мөмкин.

Шуңа күрә корткыч бөҗәкләр иялəшеп уңышсыз калдырмасын өчен, куак төбендә чүп үлән тотмаска тырышыгыз. Эшне җиңеләйтү өчен, рәт араларына тыгызлыгы 150 г/кв. м булган кара төстәге спанбонд җәеп чыгарга була. Болай эшләгәндә чүп үләннәр шактый азрак булачак.

Киңәш-табыш

СУГАН ЧЕБЕНЕННӘН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА?

Бакчачы журналист Роза НУРГАЛИЕВА суган чебененнән котылуның берничә ысулын тәкъдим итте.

- Башта суган түтәленә су сибеп чыгыгыз. Аннары 10 л суга 2 аш кашыгы нашатырь спирты салып сибәсе була.
- 10 л суга 1,5 кг яңа җыелган әрем салып, 2–3 көн төнәтергә һәм аннары сибеп чыгарга.
- Суган чебененә каршы «Мухоед», «Муравьин», «Землин», «Почин», «Баргузин» кебек препаратларны инструкциясендәгечә кулланырга мөмкин.

Психология

Яшәү серләре

Экстрасенс һәм парапсихолог Сергей ШЕЙКИН киңәшләре

1 Үзегезгә ошаганны сайлагыз. Башта десерт ашыйсыгыз килсә, ашагыз, аннары уйлагыз: сезгә кайнар ризык кирәкме соң?

2 Урамга чыгасыгыз килсә, бөтен эшегезне ташлагыз да чыгыгыз. Эш беркая да качмый, ә менә кояш болыт артына качарга мөмкин.

3 Гади әйберләр сайлагыз. Гади әйберләр һәрвакыт уникаль һәм кулланышка яраклы. Аш бүлмәсе өчен гадәти пычак күпфункциялесенә караганда файдалырак.

4 Аралашканда гади булыгыз. Кемгә нинди кием, нинди ризык ошый, кайсы сериалны караган, аларга ошыймы? Кешеләр гади әйберләрне яраталар, катлаулы нәрсәләр хакында эшегездә сөйләшү яхшырак.

5 Карар кабул итә алмый интексәгез, ашыкмагыз. Кәгазьгә үзегезнең сорагызны языгыз да әлеге сорауга ике сәгатьтән соң әйләнеп кайтыгыз. Бу вакыт эчендә башыгыз хисләрдән арынып, акыл тиешле режимда эшли башлый.

6 Дөресне түгел, ә уңайлыны сайлагыз. Бөтен дөнья кагыйдәләр белән тулган: ортопедик аяк киеме киезе, кирәкле карылыктагы матрас, «дөрес» шампуньнар. Сезгә нәрсә уңайлы – менә шул дөрес.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

ҖЫЛЫ СҮЗ ДӘ, ӨМЕТ ТӘ – ДӘВА

Хәдисләрнең берсендә: «Кеше ике төрле нигъмәтнең – вакытның һәм сәламәтлекнең кадерен белми», – диелә. Бу юлы сәхифәбезне сырхауның хәлен белү әдәбенә багышларга булдык. Сәламәтлеге мөшкелләнгән кеше белән ничек аралашырга? Өмете сүнгән сырхауга «терeләсең» дию алдау саналмыймы? Сырхау кеше янында ничек сабыр булырга? «Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ белән шул хакта сөйләштек.

aboutislam.net

:: Диндә сырхауларның хәлен белешү турында ни диелә?
– Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Мөселманның мөселман каршында алты хакы бар. Шуларның берсе – авырган кардәшенең хәлен белешү», – ди. Моннан шунысы аңлашыла: мөселман тормышта ялгыз түгел! Хәтта якын туганнары булмаса да, аның хәлен башка мөселман кардәшләр белешеп торырга тиеш. Тагын бер хәдистә: «Әгәр дә бер мөселман авыру булган мөселман кардәшенең хәлен белсә, шуның янында торган вакытта фәрештәләр аның өчен ярлыкау сорар», – диелә.

:: Сырхауның хәле сөйләшерлек булмаса, нишләргә? Аның янында үзеңне ничек тотарга?
– Кайвакытта авыруларның кешене күрәсе килмәгән чагы була. Шунысын да аңларга кирәк. Кемдер сызлана, көйсезләнә. Беренче чиратта авыруның артык хәлен алмаска кирәк. Фәрештәләр савап яза, дип, көне буе алҗытып утырырга кирәкми. Мөмкин булганча хәл сораштың, өмет уяттың да вакытында китү хәерлерәк. Синең килүеңнән авыруның хәле тагын да катлауланмасын. Аның хәсрәте болай да муеннан ашкан бит. Кешенең яшь чакта, акчалы чакта, сау чакта дус-ишләре күп була. Авыргач исә, киресе дә күзәтелә.

:: Авыру зарланса, ризасызлык белдерсә, нишләргә?
– Адәм баласы: «Нишләп миңа килде бу авыру? Нинди гөнаһларым өчен?» – дип уйлый, төшенкелеккә бирелә. Аллаһы Тәгаләнең безгә карата үз планнары, шуны аңлыйк. Тәкъдир дигәне дә бар. Авыру булмасын өчен – физик күнегүләр дә, ачык һавада булу, ялкау булмау, башкасы да кирәк. Болар барысы да пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтендә бар.

Бик нык борчылган авыруларга диндә яшәргә киңәш итәбез. Намаз уку борчулардан арындыра. Догалар кылып яшәргә була. Кыска сүрәләр укып, ике кулыңа өреп, кулларың белән тәнеңне сыпырырга мөмкин. Бу инде үзеңне өшкерү була.

– Имтихан дип көн-төн башымны бәреп укымадым. Атнага берәр көн ял иттем. Вузга укырга керер өчен математика, информатикадан имтихан нәтиҗәләре кирәк. Шуңа күрә рус теленә игътибар әллә ни җитмәде. Бары 11 нче сыйныфта гына ныклап өйрәнә башладым. Азны көтсәң, күп була икән ул! Рус теленнән 100 балл булыр дип башыма да китермәдем. Нәтиҗәне күргәч, сөенечтән елап ук җибәрә яздым. Онлайн мәктәптә шөгыльләнүемнең файдасы зур булды. Математикадан 88 балл җыйдым. Информатикадан 90нан ким җыелмас, шәт. КФУның бизнес информатикасы юнәлешенә укырга керер өчен җитәр, дип уйлыйм.

Сан

Татарстанда БДИда 158 укучы йөз балл туплаган:
рус әдәбиятыннан – 65 ● рус теленнән – 54 ● химиядән – 26 ● математикадан (профиль) – 4 ● физикадан – 3 ● тарих, географиядән – 2шәр

Ике укучы математика һәм рус теленнән 200әр балл җыйган. Алар – Түбән Каманың 10 нчы мәктәбеннән **Полина Еланская** һәм Чистайдагы 1 нче мәктәпне тәмамлаган **Александра Гришанова**.

ЕГОР СИМУХИН,

Аксубай районының Иске Тимошкино мәктәбе укучысы (физикадан 100 балл):

– Гап-гади авыл мәктәбендә укыдым. Әллә ни гаҗәпләндерә торган нәрсәләр юк. Укырга да, ял итәргә дә вакыт таптым. Буш вакытларымда әти-әниемә хуҗалык эшләрендә дә булыштым.

Миңа физикадан «бәхетле билет» эләкте дисәң дә була. Кайчак материалны бик яхшы беләсең, әмма җавапны төгәл итеп, әйтик, БДИ биремнәрен төзүчеләр теләгәнчә яза алмыйсың. Үзем укытучым белән дә, «Школово» дигән онлайн мәктәптә дә шөгыльләндем. Математика, физикадан белемнәремне арттыруда икесенең дә файдасы тиде. Туксаннан артык балл җыю максаты куйган идем. Әлбәттә, 100 балл көттем, тик шигем бар иде. Үземне вундеркинд дип санамыйм. Дөрес, БДИда авыр биремнәр дә очрый. Тик имтихан, нигездә, укучының база белемнәрен тикшерә. Шуңа күрә аннан баш тартырга кирәкми. Кая укырга барасымны әлегә хәл итмәдем.

АЛИНӘ РАХМАНОВА,

Минзәлә шәһәренең 1 нче мәктәбе укучысы (рус теленнән 100 балл):

– Миндә беркайчан да «отличник синдромы» дигән нәрсә булмады. Уку миңа җиңел бирелде. Яшермим, максимализм бар. Математикадан да 100 балл туплыйсым килгән иде. Кызганыч, килеп чыкмады. Моңа нибары 4 балл җитмәде. Апелляция бирергә җыенам. Биология сынавының нәтиҗәсе әлегә билгеле түгел.

Укырга теләге булган укучыга безнең мәктәптә барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Мин башлангыч сыйныфтан ук гел «5ле» билгеләренә генә укыдым. Бик күп фәннәрдән олимпиадада катнаштым. БДИга мине рус теленнән Резеда апа Гарипова әзерләде. Ул – бик көчле, белемле укытучы. Шуңа күрә аңа ышанып, бернинди курсларга да язылмадым, репетиторга да йөрмәдем. 11 нче сыйныфта иншалар күп яздырды. Югары балл булыр дип шикләнмәдем анысы, әмма 100не үк көтмәгән идем. Сыйныфташларым да рус телен яхшы бирде. 12 укучының баллары сиксәннән югары. БДИ кирәк, минемчә. Әмма аны үз көчләренә ышанганнар гына бирсен, ә калганнарга вузда гадәти сынау тапшыру мөмкинлеге булсын иде. Ни өчен дигәндә, БДИ укучыларның нерв системасын бик какшата. КФУның биология факультетында укырга теләгем бар. Биолог-галим яки ландшафт дизайнеры буласым килә.

АЗАЛИЯ ИБРАҺИМОВА,

Әлмәт шәһәренең Риза Фәхретдинов исемендәге 1 нче гимназия укучысы (рус әдәбиятыннан 100 балл):

– Мәктәптә «4ле» һәм «5ле»гә укыдым. Рус һәм татар телләре, физика – яраткан фәннәрем. Онлайн мәктәптә шөгыльләндем. Рус теленнән 85 балл булды, математикадан (база өлеше) «5ле»гә бирдем. Хәзер җәмгыять белеменнән нәтиҗә көтәм. Рус әдәбиятыннан 100 балл булыр дип өметләндем. Ни өчен дигәндә, җиңел биремнәр эләкте. Китаплар укырга яратам. Үз тырышлыгым белән ирештем дип уйлыйм бу нәтиҗәгә. Рәсем ясарга яратам. КФУның дизайнерлык факультетына укырга барырга җыенам. Еракка китәсем килми. Татарстанда яхшы белем алып була бит.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

ТАРИХЧЫ ЭНГЕЛЬ ТАҺИРОВ:

«БАТЫРЛАРНЫ БЕЛЕП БЕТЕРМИБЕЗ»

Советлар Союзы маршалы Константин Рокоссовский батырларча сугышкан татар егетләре турында мондый фикер язып калдыра: «Илебезне немец басып алучыларыннан азат иткән бу тарихи сугышта татар егетләре үзләрен куркусыз, ирләрчә нык һәм гаярь сугышчылар итеп күрсәттеләр». Бөек Ватан сугышында татарларның, татарстанлыларның роле нинди булган, Гитлер Германиясе СССРда яшәүче төрле милләт халкына нинди язмыш юраган?



Тарих фәннәре докторы, профессор, Дөнья мәдәнияте (ЮНЕСКО) институты ректоры Энгель ТАҺИРОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Энгель Ризакович, Германиянең ул вакыттагы эчке эшләр министры Гиммлер үзләренең бу зур җинаяте турында: «Безгә 180 млн халык каршылык күрсәтә. Бу – расалар кушылдыгы, аларның исемнәрен әйтергә тел әйләнми, йөз-кыяфәтләре бернинди дә кызгану хисе, яхшылык эшләү теләге тудырмый», – дип язып калдыра. Гитлер Германиясе планы буенча СССРда яшәүче төрле милләт халыклары нинди язмышка дучар ителергә тиеш була?

– Гитлер тарафыннан инде сугышка кадәр үк расланган «Ост» программасы буенча, немецлардан кала барлык халыклар да «тулы булмаган», «икенче дәрәҗәдәге» дип игълан ителә. Шуннан чыгып, алар башка милләтләрне юк итәргә «хокуклары» бар дип санайлар. Бу планда СССР халыкларын юкка чыгару, кирәгенчә кыскарту буенча «квота»лар да билгеләнә. Нацистларның баш идеологы Розенберг: «Безгә бу кешеләр кирәкми, аларның җирләре генә кирәк», – дип яза. Шушы планга нигезләнеп, этносара һәм конфессияара низаглар чыгару да күздә тотыла. Ә юкка чыккан илләр урынында рейх күзәтүе астында күпсанлы көчсез милли автономияләр төзү планлаштырыла. Мөгаен, монысы турында бик күпләр белми дә торгандыр: сугышка кадәр Германиядә ислам буенча бик җитди тикшеренүләр үткәрелә, Коръән китабына анализ ясала. Хәтта Гитлерга ислам пәйгамбәре буларак яңа танылу әзерләнә. Мөселман халыкларын «агарту» өчен бик зур пропаганда алып барыла. «Яңа» дин рус халкы өчен дә тәгаенләнә. Кыскасы, Германия дөнья халыклары арасында рухи яктан да төп рольне уйнарга тиеш дип күзаллана.

:: Бу план тормышка ашмасын өчен, СССРда ниләр эшләнә?

– Гитлер Германиясенең мондый адымы, киресенчә, СССР халыкларын берләштерүгә, милләтпәрвәрлекнең көчәюенә һәм, һичшиксез, илебезнең бөтенлеген саклап калуга китерә. СССРда яшәүче халыклар тарафыннан сугыш беренче минутлардан ук уртак бәхетсезлек итеп кабул ителә. Мобилизация вакытында да милләтләрне аеру булмый, хәрби частьларның составы да төрле халыклардан тора. 1943 елдан рус булмаган милләт вәкилләреннән командирлар әзерләүгә бигрәк тә нык игътибар бирелә. Боларның барысы да милләтләр арасында низаг чыгарырга омтылган нацистларга җавап буларак эшләнә.

:: Милләттәшләребез кылган батырлыклар турында бүген дә белеп бетермибез.

– Татарлар, башка милләтләр кебек үк, илебезгә тугрылыклы булып кала. Бөтен фронтларда, бөтен гаскәрләрдә батырлык күрсәтә. Бу хакта бик күп языла. Әмма, ни кызганыч, бу фактлар зур бер электрон китапка – энциклопедиягә тупланмаган. Татарларның һәм Татарстанның дошманга каршы көрәшкә керткән өлешенә төрле юнәлешләр буенча аерым-аерым анализ бирелә. Мәсәлән, фронттагы батырлыклар, колхоз кырларындагы хәлләр, фән, мәдәният, әдәбият, сәнгать өлкәсендәге вакыйгалар турында... Хәтта аларда да система юк, бары тик эпизодлар гына күрсәтелә. Булган мәгълүмат төрле китапларга, музейларга «чәчелгән». Музейлар гына түгел (ә аларны һәр урында, кечкенә генә авылларда да төзергә кирәк), Бердәм дәүләт мәгълүмати-аналитик үзәк булырга тиеш. Әйе, күп нәрсәләргә без инде бүген үк җавап таба алмыйбыз. Сугышта катнашкан кешеләр китеп бетә диярлек. Аларның саны азайган саен, кызыксынучылар да кими. Шуны гына әйтә алам: без Бөек Ватан сугышында татар халкы салган эзне югалтмаска тиешбез.

:: Мәкерле планнарын тормышка ашыру өчен, Гитлер Германиясе татарларга бигрәк тә зур игътибар биргән. Ни өчен?

– Германия, милли факторга аерым игътибар биреп, аларның үзара дошманлашуына, тарткалашуына өмет иткән. Немец тарихчылары, философлары, филологлары, чыннан да, татар тарихын энәсеннән җебенә кадәр өйрәнгән. Беренче чиратта, татарлар – күпсанлы милләт, Россиядә шактый зур урын алып тора. Икенчедән, татарлар борынгы замандан ук курку белмәс, батыр хәрбиләр булган. Шуңа да немец разведкасы кайсы фронтта татарларның күпме булуын өйрәнгән, агитация эшләрен дә үз телләрендә алып бару йөзеннән, инде сугыш башланганчы ук татарча листовкаларга кадәр әзерләнгән.

:: «Идел-Урал» легионын оештыру да шул хакта сөйли...

– Каршылык хәрәкәтендә безнең якташларыбыз зур батырлыклар күрсәтә. Анда катнашучыларның төп өлеше – дошман әсирлегеннән качып, җирле партизан отрядларына кушылучылар яки дошман тылында яшерен эшләүчеләр. Фашистлар СССРга каршы көрәшү өчен татар, башкорт һәм Идел буендагы башка халыклардан «Идел-Урал» легионы төзергә омтыла. Әмма максатларына ирешә алмыйлар: җиде батальонның берсен генә дә Көнчыгыш фронтка җибәрә алмыйлар. Белоруссия партизаннарына каршы җибәрелгән батальон тулысынча Захаров һәм Бирюлин җитәкләгән партизаннар бригадасына кушыла, икенчесе француз партизаннары ягына күчә. Тагын ике батальонның яртысы Украинадагы Сидор Ковпак җитәкләгән партизаннар армиясенә каршы көрәшергә тиеш була. Алар да партизаннар ягына авыша. Ә икенче яртысы, ышанычсыз дип табылып, Бельгиягә, Голландиягә, Франциягә җибәрелә. Калган өч батальоннан фашистлар бөтенләй ваз кичә, чөнки легионерларның күбесе качып китә яки качарга әзерләнгән була.

> Хәрби елъязмалардан күренгәнчә, Советлар Союзы Геройлары саны буенча татарлар дүртенче урында – 161 кеше. Һәлак булган татарлар – сугыш кырындагы гомуми югалтуларның 8 проценты. Кайбер чыганакларда бу сан 12 процент дип күрсәтелә. Сугышта барлык татар ир-атларының 70–80 проценты һәлак була. Фронттан 339,8 мең татарстанлы кайта алмый. Бу – ике кешенең берсе дигән сүз.

:: Белгәнебезчә, фронттагы гына түгел, тылдагы батырлыклар да җиңүне якынайтуда зур роль уйный...

– Татарстан, сугыш башланганда, шактый үсеш алган төбәк булып, илебезнең эре индустриаль-сәнәгать үзәгенә әйләнә. Инде сугышның беренче елында ук республика 600 төрле корал җитештерә. Горбунов исемендәге авиация заводы Пе-2, Пе-3 бомбардировщиклары җитештерүче бердәнбер завод була. Операцияләр өчен кетгут җепләре белән тәэмин итүче завод та бердәнбер була. Машина төзелеше, химия предприятиеләре корал җитештерергә керешә. Җиңел һәм азык-төлек сәнәгате фронтны кием-салым, аяк киеме, азык-төлек белән тәэмин итә. Татарстанга 70 сәнәгать предприятиесе эвакуацияләнә. Авыл хуҗалыгында, мәгариф, мәдәният учреждениеләрендә «Фронтка – ярдәм!» хәрәкәте киң үсеш ала. Халыктан җыелган акчага «Татарстан колхозчысы», «Совет Татарстаны» танк колонналары, «Совет Татарстаны» авиаэскадрильясы, «Кызыл Татарстан», «Чапаев», «Куйбышев» бронепоездлары төзелә.

Танк колонналары һәм авиаэскадрилья төзелешенә халыктан – 26 млн сум, хәрбиләргә бүләк фондына 40 млн сум акча җыела. Хәрби заемнар һәм лотереялар сатылып, оборона ихтыяҗларына тоту өчен 1236 млн сум акча җибәрелә. 1941–1945 елларда Татарстандагы 50 госпитальдә 500 меңнән артык яралы яки авыру солдат һәм офицер дәвалана.

:: Башкалабыз сугыш чорында фән ягыннан да алгы сызыкка әйләнә. Бу өлкәдә нинди яңалыклар була?

– 1941 елның җәй һәм көз айларында Казанга 33 институт, 39 академик, 44 әгъза-мөхбир, 1884 фәнни хезмәткәр (СССР Фәннәр академиясендә аларның саны 4 мең була) күченеп килә. Гомумән алганда, илебездәге фәнни көчләрнең өчтән бер өлеше Татарстанда урнаша. СССР Фәннәр академиясенең бик күп учреждениеләре башкалабызга эвакуацияләнә. 1945 елның апрелендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы ачыла.

:: Димәк, мондый «күченеш»ләр Татарстан тормышына шактый зур үзгәрешләр кертә?

– Бөек Ватан сугышы вакытында сәнәгать, фән өлкәсе генә түгел, татар мәдәнияте дә зур үзгәреш кичерә. Иң мөһиме, башка милләтләр белән аралашу, бердәмлек, аеруча милләтпәрвәрлек көчәя. 1942 елда әдәби хезмәткәрләрнең бер төркеме фронтта татарча нәшер ителә торган газеталарга командировкага җибәрелә. Татарстан Язучылар берлегендәге 53 кешенең 25е сугышның беренче елында ук фронтка китә. 36 язучы дошманга каршы кулына корал тотып көрәшә, шуларның 30ы һәлак була. Дөрес, икенче яктан караганда, бу хәл татар зыялылары катлавын бик көчсезләндерә.

Әйтергә кирәк, Бөек Ватан сугышы чорында татар факторын без өйрәнәбез генә әле. Республиканың Җиңүгә керткән өлеше, чыннан да, бик зур. Шул ук вакытта ул илебез ихтыяҗларын канәгатьләндерү белән бергә үзе дә үсеш ала, бу хәл аның килачәгенә шактый уңай йогынты ясый.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

АВЫЛ КӨЧЕ

ТҮБӘН БӘРӘСКӘДӘ ЭШЛИ ДӘ, ЯЛ ДА ИТӘ БЕЛӘЛӘР

Ике атнадан артык вакыт үтсә дә, Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылы халкы кичке уен хатирәләре белән яши. Барысына да кадерле, затлы чара булган ул. Ярый әле элеккеге гореф-гадәтләрне яңартып, кичке уенны яңадан кайтарганбыз, дип сөенәләр хәзер.

Күз курка, кул эшли

Бәйрәм авылдашларның дус-тату, бердәм булуын тагын бер кат исбатлаган. Өлкәннәр яшьлегенә кайтып килсә, яшьрәкләр дә, мондый бәйрәм ел да кирәк, дигән. Авыл яшәсен, гөрләп торсын өчен, күп тә кирәкми югыйсә! Оештыручылар исә, күз курка, кул эшли, диләр.

Бәйрәмне оештыручы Илгиз Хәйруллинны Татарстанда белмәгән кеше сирәктер. Ленин исемендәге хуҗалык җитәкчесе – үз җирлегендә мөмкин булган бөтен уңайлыкларны тудырган кеше. Алга китеп булса да әйтик, Бәрәскә авылында банкомат, колхоз кибетен күреп шаккаттык без. Хуҗалык җитәкчесе, халык хәләл ризык белән туклансын дип, авыл уртасында кафе да булдырган. Монда ни генә пешермиләр! Халык чират торып камыр ризыгы ала. Иртәнге унга өчпочмаклар пешеп чыга, көндезге бердә өлештән авыз итә аласың.

Кем әйтмешли, икмәк янында җыры да булырга тиеш. Кичке уен турында ул менә ниләр сөйләде:

– Баштарак, кичке уенга кеше җыелырмы дип, бераз борчылдык та. Юкка булган. Халык моңга, җырга сусаган! Ул гына да түгел, җылы, матур очрашулар урыны да булды ул. Бер авылда туып-үсеп, төрле якларга таралышкан якташлар белән күрештек. Күңелдәге хисләремне әле дә аңлап бетереп булмый. Элек тә бар иде кичке уен. Ул әле дә хәтердә. Безнең егет булып килгән, кызларга күз төшә башлаган чак. Шулай да, күңел ачу гына түгел иде ул, уеннарның мәгънәсе белән танышу, күрешү, дуслашу да иде. Әнә шуны кайтара алганга сөенәм. Быел авыл эчендәге паркка җыелыштык. Урамнар буйлап моң агыла: гармун тавышы ишетелә, җыр сузалар. Югары очлар бер төркем җырлап килә, аларны кул буенда Түбән очлар көтеп тора…

Ә икенче көнне Түбән Бәрәскәдә Сабан туе узган. Кич кабынган хисләр авыл кешесенең төп бәйрәменә дә килеп кергән. Рәхәтләнеп аралашканнар, уеннарда катнашканнар. «Мәйданны әйләнеп чыкканда игътибар иттем, кәефсез берәү дә юк иде. Мин моңа бик шат. Эшләгән барлык эшләребез – авылыбыз кешеләре өчен. Бергәләп эшләгәндә генә, тау күчергәнне беләм мин», – ди Илгиз Хәйруллин.

Болай ук булыр димәгән идек…

Авыл җирлеге башлыгы Аида Фатыйхова мәйдан тутырып халык килер дип күз алдына да китерми. Теләгәннән дә яхшырак килеп чыкты, ди ул хәзер, сөенеп.

– Без яшь вакытта да нәкъ менә шул урында халык кичке уенга җыела иде. Хәзер без анда үзара салым акчасы ярдәме белән парк ясадык. Уенның урынын да үзгәртмәдек. Элек кичке уен атналар буе дәвам иткән. Без кечкенә вакытта өч көн рәттән уза иде. Бу – Сабан туе атнасыннан соң оештырыла иде. Уйлаштык та, авылның иң актив кешеләре белән киңәштек. Гармунчыларны барладык. Аларны урамнарга бүлеп куйдык. Шәһәрдән кайтучылар да булды, – ди Аида ханым.

Без сөйләшеп йөргәндә, кичке уенда гармун тартып йөргән Рәшит абый Гаптрәхимов очрады.

– Без бит кечкенәдән шул уеннарда катнашып йөргән егетләр. Йөрәк җилкенде, дулкынланудан каз тәннәре чыкты. Әйтерсең, яшьлегебезгә кайттык! Ярый оештырырга уйлаганнар әле. Кайткан кунакларга да ошады, – ди Рәшит абый. – Монда кешеләр бер-берсенең хәлен сораша. Ярлар насыйпларын таба. Бала-чага да рәхәтләнеп уйный. Онытыла язган йолалар кире кайтты. Беләсезме, гармунчылар да бетеп бара бит хәзер. Элек гармун тоткан кешенең дәрәҗәсе дә бар иде. Хәзер бөтенләй башкача. Ышанасыңмы, юкмы, авыл җирендә гармун уйнаучы табу кыен хәзер. Элек менә мин яшь чакта бик кадерле идем. Күтәреп кенә йөртмиләр иде инде. Урын түрдә булды. Кем солдатка китә, кемдә туй… Кызлар да ярата иде. Гармунчыга карата булган менә шул абруйны кире кайтарасы иде.

Рәшит Гаптерәхимовка – 60 яшь. Картаерга исәбе юк әле.

– Ике улым да кичке уенга кайтты. Алар җырладылар. Аннары яныма килеп, әти, син дә җырла әле, диләр. Мине дә күрсәтәсе килә аларның, әниләрен дә. Хатыным Фәридә дә җырлый. Без урам башыннан җыелышып җырлап төштек, – ди Рәшит абый. – Хәзер бит кешеләр үз эченә бикләнде. Нинди бәйрәм булса да, кайткан кунагы, гаиләсе белән бакчасында шашлык пешереп, төтен иснәп утыра. Үзара аралашу бетте. Йөрәк бик сыкрый иде шуңа. Ә бит булдырып була икән. Бер тиен акча тотмыйча да бәйрәм ясап була!

Кайда йоклаганны да белмәдем

Назилә һәм Әдһәм Гайнуллиннар да яшьлекләренә кайтып килгән.

– Күпләр кичке уенда очрашса да, без Әдһәм абыең белән клубта таныштык. Бик ялындыра торган кыз идем. Элек бит егет ташлап китәр дип куркып тору юк иде. Озаттырмый да идек. Аннары безнең заман кызлары тыйнак иде. Кая ул егет күзенә күрену! Әдһәм абыең армиядән ялга кайткач, ялындырган идем. Икенчегә юлны борды бит. Башка кызны озата башлады. Сер бирмәдем. Әмма китәр алдыннан мине биергә чакырды. «Назилә, ничек булса да, без бергә булачакбыз», – диде. Армиядән кайткач, ялындырып йөрмәдем инде. Ике елга якын очраштык та өйләнештек. Шөкер, 55 ел бергә гомер итәбез, – ди Назилә апа. – Майның 12сендә операция ясаткан идем. Күңелне тыеп буламыни?! Кичке уенга чыктым. Әдһәм абыең да барды, Казаннан баянын күтәреп улым да кайтты. Ул уйнады да, җырлады да. Әтисе белән бергә өздерделәр генә. Арыганмын. Ул көнне кайда йоклаганымны да белмим. И сеңлем, шулкадәр матур бәйрәм булды! Күңел тагын күтә. Исәнлектә яшәп, киләсе елларда да кичке уеннарны күрсәк иде. Күңелем тулды. Мин генә түгел, бөтен авыл халкы оештыручыларга рәхмәт укый. Безнең буынны яшьлегенә кайтарсалар, яшьләрнең күңеленә күпме рухи азык салды алар. Авылны уеннары, гореф-гадәтләре белән генә яшәтеп була. Бу эш дәвамлы булсын!

…Түбән Бәрәскәдән гаҗәпләнеп һәм сөенеп кайттык. Авыл рухы белән хуҗалык көче берләшкән бирердә. Тормышлары әнә шуңа корылган. Илгиз Хәйруллин белән сөйләшеп торганда яныбызга таякка таянган бер ханым килеп исәнләште. Хәл белешкәч, ханым хуҗалык җитәкчесенә гозерен җиткерде: «Илгиз абый, өйдә ятып ардым. Аякларым төзәлде инде. Таяксыз да йөри алам. Бөтен эшне эшлим. Эшкә чыгыйм әле», – диде. Җитәкче озак уйлап тормады, дүшәмбедән эшкә чыгарга кушты. «Уңган терлекче, сыер савучым иде. Аягына операция ясадылар, авыр эш ярамый инде хәзер», – диде ул, ханым китеп баргач һәм авыл җирлеге башлыгына дәште: «4 сәгатькә эшкә чыгарыйк, акчасын тулы итеп түләрбез».

Тарихи белешмә

1556–1557 еллардан Верески исеме белән билгеле. 1769 елда авылда Ибраһим Борнаев акчасына беренче җәмигъ мәчет төзелә. XX йөз башында авылда 2 мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. 1913 елда авылда башлангыч мәктәп ачыла. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостена, 1920 елдан ТАССРның Арча кантонына керә. 1930 елның 10 августыннан – Тукай, 1938 елның 25 мартыннан – Әтнә, 1959 елның 12 октябреннән – Тукай, 1963 елның 1 февраленнән – Арча, 1990 елның 25 октябреннән – Әтнә районында. Хәзер Түбән Бәрәскә авыл җирлеге үзәге.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

АЛИНӘ ШӘРИПҖАНОВА:

«БЕЗГӘ КҮП КИРӘКМИ, АЛТЫН КАШЫК СОРАМЫЙБЫЗ»

Затлы, зәвыклы җырчылар бармак белән генә санарлык. Ул элек тә шулай булган, хәзер дә. Аларның берсе – Татарстанның халык артисты Алинә ШӘРИПҖАНОВА. Иң күп макталганы да, тәнкыйтьләнгәне дә ул. Җырчының тавыш үзенчәлеге нидә? Телне өйрәнүдә нинди кыенлыклар бар? Алинә фикеренчә, мәдәният өлкәсендәге иң төп өч проблема нәрсәдән гыйбарәт? Әңгәмә әнә шул хакта.

:: Җыр ул – ...
– ...тормышымның мәгънәсе, тугры иптәшем. Ул мине канатландыра, рухландыра, илһамландыра да. Юнәлеш бирүче дип тә әйтер идем.

:: Алинә, сез бит татар эстрадасына, дөресрәге, «Барс Медиа»га эләккәнче, русча, инглизчә җырлый идегез. Татар эстрадасын сайлаганга үкенмисезме? Рус эстрадасын гына алсак та, анда мөмкинлекләр күбрәк бит.
– Юк, мин русча, инглизчә генә түгел, бәләкәйдән үк татарча да җырладым. Бу күбрәк гаилә бәйрәмнәрендә була иде. Ә инде сәхнәдә татарча җырламауга килгәндә, ул чакта минем үземә атап язылган «хитовый» җырым булмады. Аннары Ләйсән Мәхмүтова «Сине көтәм» дигән җыр бүләк итте һәм мин аны Фәрит Таишевка күрсәттем. Шуннан «Барс Медиа» белән эшли башладым. Юк, татар эстрадасын сайлавыма бер дә үкенмим. Дөрес, рус эстрадасында мөмкинлекләр зуррак, ләкин... Әйе, минем русча җырларым да шактый. Без Эльмир Низамов һәм башка авторлар белән төрле телләрдә язарга, иҗат итәргә тырышабыз. Әмма татар телендә җырлау миңа якынрак. Мин – барыбер татар җанлы кеше!

:: Тормыштагы хәлиткеч мизгелне искә төшерик әле.
– 2012 ел иде ул. Бу елны «Барс Медиа» компаниясе оештырган «Яңа сулыш» дигән концерт программасында катнаштым. Шунда кирәк бит: микрофоным әллә нишләде. Бер сүз әйтеп өлгердемме икән, юкмы, сүнде дә китте. Нишлисең, микрофонсыз җырлап чыктым. Концерттан соң коридорда Камал театрының ул чактагы директоры Шамил Закиров көтеп тора. «Алинә, тавышыңның нинди көчле, бай булуын үзең аңлап та бетермисеңдер әле. Сиңа бит сәхнәдә беркем дә кирәкми! Бу тавыш белән берүзең чыгып, рәхәтләнеп вокаль моноспектакль куеп була. Шоу дип, бизәлешләр дип, башыңны катырма. Монда озак уйларга кирәкми, үз концертыңны оештыр». Янәшәдә генә Камал театры артисты Илдар Хәйруллин, Салават Фәтхетдинов басып тора. Билгеле, мин югалып калдым. «Шамил абый, минем концерт оештырырга финанс мөмкинлекләрем юк шул», – дип кенә әйтә алдым. Шамил абый исә: «Бүгеннән әзерләнә башла, сиңа Камал сәхнәсен бушка бирәбез», – дип, мәсьәләне хәл итте дә куйды. Хәлиткеч мизгел иде бу... Мин, дулкынланып, әзерләнә башладым. Бер көн кала, концертның режиссеры Илдар Хәйруллин шалтыратып: «Алинә, син хәзер утырып торасыңмы? Утыр әле, балам, мин сиңа аяктан егарлык хәбәр җиткерәм. Шамил Зиннурович вафат...» – димәсенме?.. Башта аңламадым. «Инфаркт» сүзен ишеткәч, хастаханәдәдер дип өметләнәм бит әле. Әле дә авыр... Концертны чигердек, билгеле. Тамашачы алган билетларын кире кайтармады, зал тутырып килде. Мин исә шушы вакыйгалардан соң сәхнәгә тугры булып калырга, тамашачыны алдамаска, һәрвакыт «тере» тавыш белән җырларга, мәгънәле җырлар гына башкарырга сүз бирдем. Башкача ул Шамил абый теләгәненә хыянәт булыр иде. Аннан соң бик күп вакыт узды. Әмма Камал театры бинасына атлап кергән саен, һаман да күз алдымда Шамил абый сурәте тора, колагымда аның сүзләре яңгырый.

:: Тормышта төп киңәшчегез кем?
– Тормышта киңәшчесез булмый. Җыр сайлаганда иң беренче интуициягә таянсам, әнием, гаиләм киңәшләренә дә колак салам. Ирем төпле киңәшләрен бирә, кызым инде хәзер кием сайлаганда үз фикерен әйтә. Шулай да, иҗатта остазым Винера Ганиева – төп таянычым.

:: Җыр сайлаганда ниндидер кагыйдәләрегез бармы?
– Туганнарны сайлап алмыйлар бит, Ходай Тәгалә аларны үзе бирә. Җырлар да миңа Ходай бүләге кебек. Сиңа насыйп булган җыр ул башта ук якын була: мәгънәсе ягыннан да, көе ягыннан да.

:: «Әллүки», «Гөлҗамал»ны башкару алымыгыз үзенчәлекле. Ул нәрсәгә корылган, аңлатып үтегез әле. Шунысы да бар: кемдер кабул итә аны, кемдер юк. Ни өчен кабул итмиләр, дип уйлыйсыз?
– Сәхнәгә чыкканда, үзенчәлекле итеп башкарыйм әле дип чыкмыйсың инде. Ул үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Шул ук «Гөлҗамал» бүген бер төрле, иртәгә бөтенләй икенче төрле яңгырарга мөмкин. Дөрес, нинди тамашачы тыңлаячагын исәпкә алам. Мәсәлән, авылда халыкчан башкарам, монда тамашачының төрле тәҗрибәләрне аңламаячагын һәм кабул итмәячәген яхшы аңлыйм. Ә Опера театрында чыгыш ясарга туры килсә, академик юнәлешне сайлыйм. Гомумән, мин күбрәк әзерлекле тамашачы алдында чыгыш ясыйм. Алар исә гади башкаруны түгел, эксклюзив чыгыш, яңалык көтә. Андый чакта микс ясыйсың, төрле алымнар кулланасың. Чыгышларымны кабул итмәделәр дип әйтә алмыйм, тамашачыдан андый реакция килгәне юк. Бер тапкыр гына «урыс кебек улыйсыз» дип әйткәннәре булды. Мөгаен, ул кеше халыкчан башкаруны теләгәндер. Нәрсә дип әйтим: мин – совет заманында туган, совет тәрбиясе алган кеше. Әнием Любовь Анатольевна – рус милләтеннән, ул – тормышымдагы иң кадерле, иң матур, иң киң күңелле кеше, һөнәре буенча педагог. Мин аны чиксез яратам. Әтиәни берәү генә. Аллаһы Тәгалә миңа шушы гаиләдә туарга, шушы тәрбияне алырга һәм татар җанлы кеше булып формалашырга насыйп иткән, мин моның белән горурланам. Әйе, миндә украин, поляк, рус, татар каны ага. Яңадан тормыш башларга туры килсә дә, шушы язмышымны үзгәртмәс идем. Әниемнең аякларын үбеп рәхмәт әйтәсем килә. Чөнки бүгенге Алинә Шәрипҗанова – аның җимеше, аның тырышлыгы.

:: Сәхнә нәрсәне кичерми?
– Сәхнә дисциплина бозганны яратмый, монда үзеңне гел тонуста тотарга кирәк. Бу – сәламәтлекне кайгырту, яхшы кәефтә булу дигән сүз. Тагын ул ясалмалыкны кичерми һәм үзенә тугры булуны таләп итә. Димәк, сәхнә хыянәтне, ялкаулыкны кичерми. Минем репертуарымда 600дән артык җыр, бәлкем, күбрәктер тә. Мин аларның барысының да сүзләрен белергә тиеш.

:: Тәнкыйтьне кабул итәсезме?
– Кешеләр никадәр булса, фикерләр дә шулкадәр. Тәнкыйтькә беркайчан да ачуланганым да, үпкәләгәнем дә юк. Аек акыл белән кабул итәм. Иң кызыгы: аның бит кайсы башкаруның дөрес, кайсының ялгыш икәнен дә төгәл генә әйтеп бирә алучысы да юк. Мәсәлән, мәрхүмә әбием Камилә – Саратов өлкәсеннән, ул халык җырларын киң итеп, ачык аваз белән җырлый. Ә кайбер кешегә бу киңлек ошамый.

:: Татарстан Рәисе каршында Мәдәният Советы бар. Әгәр сезне шушы комиссия алдында чыгыш ясарга чакырсалар, мәдәнияттә нинди төп өч проблеманы аерып күрсәтер идегез?
– Дәүләт оешмаларында эшләгән артистларга игътибар комачауламас иде. Мәсәлән, без Казан шәһәр филармониясендә эшлибез һәм, килешәсездер, безнең чыгышлар радио-телевидениедә сирәк ишетелә. Бүген массакүләм мәгълүмат чаралары ротациягә эшли. Бу – җырны эфирга чыгару өчен дә түләү дигән сүз. Ул бик кыйммәт тора. Шушы юнәлештә ярдәм булса, әйтик, грант системасы эшләнсә, яхшы булыр иде. Эфирларның сыйфаты да яхшырыр иде, миңа калса. Икенчедән, гастрольләр оештыруда ярдәм итсеннәр иде. Безгә бит күп тә кирәкми, кем әйтмешли, алтын кашыктан ашамыйбыз. Казан чаралары белән генә чикләнмичә, татар яшәгән бөтен җирләрне колачлыйсыбыз килә, шул гына. Өченчедән, татар балалары өчен радио булдырыйк, дип әйтер идем. Яисә Татарстан радиостанцияләрендә балалар өчен аерым татарча тапшырулар эшләнсен иде. «Бимрадио»да «Татарча өйрәник» дигән тапшыру бар иде. Шәп иде ул. Гади, үтемле, истә кала торган. Булсын иде шундый тапшырулар «Болгар радиосы»нда да, «Татар радиосы»нда да. Берсе дә артык булмас иде.

Блиц-сораштыру

– Алинә Шәрипҗановадан хатын-кызларга 3 киңәш.
– Хатын-кыз мәхәббәт өчен туган, шуны онытмагыз. Үзегезне яратыгыз, кабатланмас якларыгыз белән горурланыгыз. Камилләшегез, дөньяны яратыгыз.
– Ир-егетләргә 3 киңәш.
– Намуслы, ышанычлы булыгыз. Гаиләгә тугрылыклы булыгыз. Ватанга тугры булыгыз.
– Сез – үз бәясен белә торган җырчы. Хәзер дә шулаймы?
– Хәзер дә бернәрсә үзгәрмәде.
– Сезнең өчен тыелган тема бармы?
– Тыелган тема юк, теләсә кайсы сорауга җавап бирә алам.
– Нәрсә ул – бәхет?
– Репертуарымда «Гомер бәйрәме» (Тәслимә Низами сүзләре) дигән җыр бар. Анда «нәрбер туган көнем – үзе бәхет, күңелкәем минем яшь һаман» дигән сүзләр бар. Яшәү – үзе бәхет. Шуңа инанып, шулай дип уйлап яшәргә кирәк.

:: Тормыш кагыйдәләрегез нинди?
– Тугры булырга. Гаиләгә. Ватанга. Сәхнәгә.

:: Хәтерлим әле, беренче әңгәмәләрдә татарча бик начар сөйләшә идегез, хәзер бик шома. Җыр ярдәмендә телгә өйрәнеп буламы?
– Телне үзләштерергә җыр ярдәм итә, билгеле. Күбрәк китап укырга, сөйләшергә кирәк. Ниндидер телне өйрәнәм дисәң, шул телнең мохитен булдырырга кирәк. Икенчедән, оялмаска. Шундый кешеләр бар: матур гына сөйләшә башлыйлар да тукталалар. Акценттан оялабыз, сүзләрне дөрес кулланмыйбыз дип куркабыз, диләр. Курыкмаска кирәк, ничек булса да сөйләшергә. Тора-бара тел шомара ул.

:: Балаларыгыз татарча беләме?
– Балаларым татарча сөйләшергә тырышалар, татар мәктәбендә укыйлар. Мин аларга, оялмагыз, татарча сөйләшегез, дип әйтәм. Үзем, кая гына барсам да, татарча сөйләшәм.

:: Кайвакыт җырчылар интернетта проблемалар, бәхәсле моментлар белән бүлешә. Моңа ничек карыйсыз? Ялгышмасам, үзегез дә энегез белән булган аңлашылмаучылык турында сөйләгән идегез кебек.
– Мин алдаша алмыйм, бөтен бәла шунда. Мәсәлән, бер тапшыруда алып баручы энекәшем хакында туп-туры сорады һәм мин турысын әйтеп җавап бирдем. Икенче тапшыруда да шундый хәл булды. Кемдер яшерә белә, а минем – эчемдәгесе тышымда шул. Ләкин мин андый хәлләрне популярлыкны арттырырга дип махсус оештырмыйм.

:: Сезнең һөнәрнең нинди кимчелекләре бар?
– Безнең һөнәр тырышлык ярата. Ялкауланырга һич кенә дә вакытыбыз калмый.

:: Ә уңай яклары?
– О, ул гел плюслардан гына тора! Күңел ачасың, аралашасың, матур күлмәкләр киясең (*көлә*).

:: Балаларыгызны нәрсәдәндер тыясызмы? Алар да сәхнә кешесе булырга теләсә, риза булачаксызмы?
– Начар нәрсәләрдән тыябыз. Ә калганы – үз кулларында. Сәхнә кешесе булам дисәләр, тыймаячакбыз. Булдыра алганча ярдәм итәрбез. Нинди генә һөнәрне сайласалар да, күңелләре саф булып калсын, ярдәмчел, тәртипле, миһербанлы булсыннар.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Ахыры. Башы 9, 16 июнь саннарында

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА

КАРТЫЙ

(ХИКӘЯ)

Өченчесе... Тик боларны күзәтергә вакыт юк, картый Амиләне алга әйди. Табын идәндә, алларына кызыл башлы сөлге салып, кайсы аяк бөкләп утырган, кайсы хәтфә тышлы күпчеккә таянган. Аларны аягөсте торып каршы алдылар. Картый Амиләне янәшәсенә – түргә утыртты. Өстәлдәге ризыклар әле юка япма белән капланган; муллаттәй каршына нәни савыт белән тоз куелган. Ул җайлап утырды да, тамагын кыргалап торгач, дога укый башлады: «Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рәхииим...» Амилә табын тирәсенә җыелган карчыкларны күзәтә башлады. Һәрберсе «менә мин кем!» дигәндәй кукраеп утыра, вакыт-вакыт чәчләренә үргән чулпыларын чылтыратып ала. Борын астыннан гына нидер сөйләшеп алалар үзара. Шундый эре булып кылансалар да, ара-тирә картыйга сагаюлы караш ташлап алалар. Хөрмәт итәләр, димәк. Амилә ирексездән картыйны янә үзләренең директоры белән чагыштырып алды. Директордан да һәммәсе шүрли мәктәптә. Ләкин ул үзгә бертөрле шүрләү, курку катыш... Ә монда картыйга карата ниндидер соклануы шүрләү иде. Амилә, үзе дә сизмичә горурланып, аңа карады: бер башка югары утыра иде картый! Әнә бит ул нинди олы, ничекләр матур итеп борын эченнән суза: «Әл-хәмдүлилләәһи раббил-галәмииин...»

Табында өч самавыр гөжләп кайнап утыра иде. Картый, үрелеп, янәшәдәгесенең торбасына лимон кабыгы салды. Өйгә, борын эчләрен кытыклап, хуш ис таралды. Бик озаклап, тирләп-пешеп, чәй эчтеләр. Әбиләрнең шиңгән йөзе терелеп, бит урталарына шәфәкъ яктысы йөгерде, маңгайларына чәчрәп чыккан бөрчек-бөрчек тир тамчыларын кызыл башлы сөлгегә сөртә-сөртә, әллә кайчан булган хәлләрне кичә генә кичергәндәй сөйли-сөйли, самавырны егып салганчы кинәнде карчыклар. Аннары табынга табак белән ит килде, киленчәкләр һәркемгә токмачлы аш өләште. Тутырган тавык чыкты, каклаган каз... Амилә китерелгән ризыкның санына чыга алмады, ялыкты, урыныннан торып тышка йөгерәсе килә башлады. Тик картыйны калдырып ничек йөгерәсең? Әнә ул тагын балда катырылган һавалы камырны аның авызына китерә: «Кәләвә! – ди, – кап әле, наныем, сиңа тансык ул». Амиләгә авызын ачасы гына кала.

Амилә, картыйга ияреп, җәй дәвамында шундый мәҗлесләргә еш йөрде. Ул моңа шундый күнекте, мәҗлес озаграк булмый торса, күңеле ник төшә иде. Сыйланып йөрү, матур сүзләр ишетү җанга сары май булып ятса, сәдака өләшү дә ошый иде Амиләгә. Муллаттәй белән янәшә утырган шәкерт кызга әби-чәби яхшы ук тамыза, әбекәе махсус тегеп биргән капчыгы тулып килә иде инде кунак кызның.

– Яле, – дип, мәҗлес кызып кына җиткәч, картый Амиләгә эндәшә: – нәберәм, йөрәк маем, «Күл һу Алла»ны укып бир әле боларга, шаккатсыннар! – Һәм ул сыңар кулы белән тирә-ягын ханбикәләрчә иңләп ала.

Кем шаккатсын инде, мәҗлес саен шул хәл! Картыйның әмиранә кулы хәлсезләнеп итәгенә килеп ятуга, Амилә борын эченнән генә сузып (Мисыр мәкаме, ди картый) көйли башлый: «Күл һу Аллаһу әхәд, Аллаһу сәмәд...»

Сүрә озын түгел, шуңа Амилә ашыкмыйча көйли, авазларны рәхәтләнеп суза, һәр мәҗлестә үзеннән яңа аһәңнәр өстәргә тырыша. Әбиләрнең исе китә, «машалла» да «бәрәкалла» дип, шәһәр кызын мактыйлар. Хуҗабикә урысча сөйләнеп йөргән оныкчасының кеше-кара күрмәгәндә йомшак җиренә чәбәкләп ала, тегесе сөрән ярып урамга чыгып йөгерә, тышта әле аның ачы тавышы озак яңгырый.

Ләкин Амиләнең аларда эше юк, картый аны үз кырыннан ерак җибәрми. Иртә таңнан алар икәү урманга китә, кайтуга бакчада эшлиләр, урамда тырай тибәргә кызыйның вакыты юк иде. Көннәр шулай үтә торды.

Беркөнне төш вакытларында алар өенә өч ир-ат килеп керде. Карчыклар шактый ук шомландылар да бугай. Нигә халыкка афьюн таратасың, дип, элекке замандагы кебек алып китсәләр картыйны? Аллам сакласын, әллә ни көтәргә була болардан.

– Айнизямал Мухаметзяновна здесь проживает?

– Амиләне качыр! – дип кычкырды әбекәй. Аның кычкыруында да мантыйк бар, бу вакытта инде Амилә «Колһуалла»дан «Әлхәм» сүрәсенә барып җиткән иде.

Бераздан аңлашылды: район үзәгеннән үк картыйны йөз яше белән котларга килгәннәр икән. Түшенә «Йөз яшь!» дигән медаль дә тактылар. «Алатырдан сезнең өчен махсус ясатып кайтарттык», – диде башлыклары – депутат. Берсе медаль такканны черт-черт сурәткә төшерде. Гәҗиткә чыгарабыз, диделәр. Карчыкларның аңа исләре китмәде, авылда гәҗит алучы кеше юк иде. Озак тоткарланмады чакырылмаган кунаклар, саулык-сәламәтлек, озын гомер теләп, дөбер-шатыр килеп чыгып та киттеләр. Картый тагын нәрсәгәдер өметләнгән иде дә – йөз яшькә бит һәркем барып җитми! – нишлисен, медаль дә – бүләк. Кулъяулыгына төреп, сандыгына салып куйды.

Амилә авылдан китмәскә булды. Шәһәргә кунакка гына баргалап килер ул, әлбәттә. Әти-әнисен күреп... Тик кеше исәпли, тәкъдир хисаплый, диләрме әле? Август аеның соңгы көннәре иде. Әтисе, иртәгә авылга кайтасын белдереп, телефоннан чылтыратты. Өч карчык та, тызбыз килеп, кунак каршыларга әзерләнә башлады. Картый йомыркалар алырга дип кетәклеккә менеп киткән икән. Шунда баскыч әйләнеп киткән дә... Картәнәсе белән әбекәе аны, мышный-мышный көчәнеп, өйгә алып керделәр, караватына салдылар. Амилә дә булышты. Дөресен әйткәндә, картый авыр түгел иде. Җиңел иде ул. Ыңгырашмады, тып-тын гына ятты. Амилә, аның чатнаган иреннәренә юеш сөлге тидереп, янәшәсендә утырды. Ул аны үләр дип уйламады да. Аның картые бит ул! Үлемне күз алдына китерә алмый иде Амилә. Ләкин күзаллый да кебек үзе, тик бит картый аңа бирешеп торамы инде? Әле бит аларның кичкә бәби туена барасы бар.

Икенче көнне әтисе кайтып җитте. Ул Амиләне алырга дип кайткан иде. Картыйның урында ятканын күреп, бик пошынды. Нишләргә белми, өйдә ары-бире йөренде. Өмет юк... өмет юк. Аны мондый хәлдә ташлап китәргә дә әллә ничек... Нишләргә?

Картый аның гасабилануын аңлады, әлбәттә. Ишарәләп янына чакырды.

– Алып кит Амиләне, – диде ул, газаптан чәрдәкләнгән авазларны өзек-өзек чыгарып. – Бәхил булыгыз.

– Торыйк әле бераз, – дигән булды әтисе.

– Әле мин берничә көн җәфаланам. Көтмә. Амиләнең дә исән килеш исендә калыйм.

– Тереләсең әле син, картый. Моңарчы үлмәгәнне...

Картый елмайган кебек булды. Учында йомарланган кәгазь акчаларны торынына сузды: «Өлгермәдем. Үзең куярсың инде ташны...»

Күзен йомып, озак кына эндәшми ятты. Амилә мышык-мышык елый, әтисе кырын-кырын сәгатенә карап ала...

– Сандыктан... мидалны... Килен! – Картәнәсе, зур сандыкны ачып, теге депутат абый алып килгән медальне алып килде.

– Амилә, – диде картый. – Менә бу сиңа...

Амилә медальне учына йомарлады.

– Йөз яшеңә җиткәч, син дә аны нәберәңә тапшырырсың.

Машина, моңаеп торган ташландык авылларны узып, киң кырлар аша Алатырга ашыкты. Әтисе: «Амалия, Амалия», – дип эндәшеп караган иде дә, кыз йоклаганга сабышып җавап бирмәде. Сөйләшәсе килми иде аның. Күңелен картый турында уйлар биләп алган иде. Ничек икән аның хәле? Тиздән Аллаһы Тәгалә белән күрешәм, дигән иде бит. Ул күрешер дә. Үзе дә бик өлкән яшьтә бит. Фәрештәләр кабул итәр, юлын бүлмәсләр. Аллаһы Тәгаләгә нәрсә әйтер икән картый? Амилә турында берәр сүз кыстырыр микән? Ул елмаеп куйды. Әллә ул картыен белмиме? Кыстыру гына түгел, авыз тутырып әйтер: Амилә бик тәрбияле, тәртипле кыз, дияр. Синең бер һәм бердәнбер булуыңа ышана ул, дип тә өстәр.

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

П2435 – җомга саны **512 сум 70 тиен**
П2409 – атнага дүрт тапкыр чыга **1227 сум 30 тиен**

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!

Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июнена кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»
*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ **3 100 сум**

Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Адрес:
Салих Батыев ур., 1 йорт

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

Реклама 18+

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.



Әз-мәз мәзәк

Әтисе сәгатьнең батареяларын алыштыргач, кызына мөрәҗәгать итә:

– Иске батареялар кирәк түгелме?

– Нәрсәгә ул миңа, әти?

– Белмим, экология буенча докторлык диссертациясен син язадың бит, мин түгел.

* * *

Бәрәңге боламыгы белән кәтлит ашаганда иң авыры – аларны бер тизлектә ашау: икесе дә бертигез кимергә тиеш.

* * *

– Матурым, йоклар алдыннан миңа берәр матур сүз әйт әле?

– Ашларың тәмле булсын!

* * *

Эшкә алганда:

– Excel программасына мөнәсәбәтегез?

– Мин аны куралмыйм!

– Аңладым, якыннан таныш икәнсез.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: баһадир, ал, ешлык, тастымал, Лютер, лол, Паша, Хәйруллин, җаем, әрҗә, ашкын, Тесла, чәч, чуар, Уг, им, Як, энә, Ани, ир, Әхсән, Сөмбел, альбом, Инь, бәйләм.
Вертикаль: Батулла, Чирәм, ала, Ярдәм, Ан, сорых, Асель, аут, әҗәт, янә, йә, Ечкин, ре, су, Соб, Реал, пумала, өмә, шлюп, шар, ял, Ташлык, бил, еш, унике, Акура, Нөнәгәр, ләм.

Беләсең килсә...

1 Бу металлны элек фотографлар төшерәсе объектны яктырту өчен кулланган:
а) магний;
б) родий;
в) рутений.

2 Бу җәнлекнең икенче атамасы – кугуар:
а) ягуар;
б) пума;
в) пантера.

3 Мәкальне дәвам ит: «Сүзе яманның...»:
а) күзе яман;
б) үзе яман;
в) тезе яман.

4 Афзал Шамов язган әсәр ничек атала?
а) «Сара мәче»;
б) «Сары мәче»;
в) «Соры мәче».

Җаваплар: 1.а); 2.б); 3.б); 4.в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14253 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 288

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+